Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Зур Тигәнәле муниципаль бюджет төп гомумбелем бирү мәктәбе

**“Каралды”**
ММБ җитәкчесе

/Ахметзянова И.Р./
Беркетмә №1, 26.08.2022

**“Килешенде”**
Зур Тигәнәле төп белем бирү мәктәбе укыту - тәрбия эшләре буенча директор урынбасары

/Сунаева Л.Х./
31.08.2022

**“Расланды”**
Зур Тигәнәле төп белем бирү мәктәбе директоры

/Сайфутдинова А.Н./
Приказ № 131 от 31.08.2022

# 2022-2023 нче уку елы өчен
# Зурлар төркеменә перспектив план

Төзеделәр:
Хайбуллина Энҗе Нәбиулловна.
Мустафина Эльмира Ринатовна.

Педагогик киңәшмә
утырышында кабул ителде
Беркетмә №1, 31.08.2022

# Эчтәлек.


1. Тәрбиячеләр турында белешмә.........................................................................3

2. Төркемнең материаль – техик нигезе .....................................................................4

3. Тәрбия һәм белем бирү процессының эчтәлеге....... ..............................................7

4. Программаның төп максатлары..........................................................................8

5. 3-7 яшьлек балаларның психик үсешенең яшь үзенчәлекләре.............................8

6. Көндәлек режим................................................................................................ 11

7. Җәйге чорга көндәлек режим .........................................................................11

8. 2022 -2023 уку елына шөгыльләр челтәре.......................................................... 12

9. Математикага перспектив план .........................................................................13

10. Сурәтләү һәм кору эшчәнлеге өчен перспектив планлаштыру ............................28

11. Комплексно-тематическое планирование по русскому языку ............................70

12. Ана теленнән перспектив план .........................................................................80

13. Ата-аналар белән эш планы ..............................................................................85

14. Милли – җирле компонент (НРК) ......................................................................87

15. Кулланылган әдәбият ......................................................................................90

## *Тәрбиячеләр турында белешмә*

1. **Хайбуллина Энҗе Нәбиулловна**

- **Белеме** - Яр Чаллы дәүләт педагогия институты.
- **Эш стажы** – 36 ел
- **Категориясе** - 1нче категория.

2. **Мустафина Эльмира Ринатовна** .

- **Белеме** - Татар дәүләт гуманитар-педагогия университеты.
- **Эш стажы** - 32 ел.
- **Категориясе** - юк

**Төркемнең материаль-техник нигезе.**

Барлык эксплуатацияләнүче бүлмәләр Санпин, хезмәт саклау, янгын сүндерү иминлеге, антитеррористик иминлек таләпләренә туры килә.

**Җиһазлау.**

**Төркем бүлмәсе:**

- практик эшчәнлек өчен яракланган балалар җиһазлары;

- китап почмагы (яшь үзенчәлекләренә яракланган китаплар, әкиятләргә иллюстрацияләр, пазл уеннары "Әкиятне җый", "Әкиятне танып әйт" уены, язучылар портретлары);

- тасвирлау эшчәнлеге өчен почмак (кәгазләр, карандашлар, пластилин, балчык, кайчынар, трафаретлар, мөһерләр, калыплар, буяулар, гуашь, балавыз акбурлары, кайчылар, пумалалар, бизәү үрнәкләре, тозлы камыр, яраксыз материаллар, сәнгать жанрларының үрнәкләре рәсемнәре һ.б.;

- уен җиһазлары, с/р уеннар ("Гаилә", "Шихаһәнә", "Төзелеш", "Сату үзәге", "Мода йорты", "Матурлык үзәге") уеннарга атрибутлар;

- театр эшчәнлеге почмагы (театр төрләре папкасы; "Әкиятне танып әйт" д/у, өстәл, баркмак, шәүләле, кул һ.б театрлар);

- музыкаль эшчәнлек почмагы (музыкаль инструментлар: курай, шөлдерле барабан, барабан, гармун һ.б. музыкаль инструментлар, күргәзмә материаллар, дидактик уеннар, композиторлар портретлары, д/у);

- табигать почмагы (яшелчә, җимеш , гөмбә муляжлары, күргәзмә материаллар, дидактик уеннар, өстәл уеннары "Балык кайда качкан?" һ.б., хезмәт почмагы: алъяпкычлар, лейкалар, кечкенә көрәкләр, тырмалар)

- конструкцияләү почмагы (төрле төрдәге конструкторлар: "Лего", "Агач", "Зур шакмаклар")

- кул-бармак эшчәнлеге почмагы (шнуровка, массаж туплары, «Бармаклар» агач тактада ясалган уен, "Энә белән муенса җыябыз" өстәл уеннары; лабиринтлар һ.б)

- өстәл, дидиактик, үстерүле уеннар почмагы;

- мини музейлар почмагы (йорт хайваннары, фантиклар музее)

- "Халкыбызның йолалары" почмагы (күргәзмә материал, балаларның яраксыз әйберләрдән ясалган тарихи манаралары, дидактик уеннар, пазллар);

- кызыклы математика почмагы (Дьенеш блоклары, Киюзенер таякчыклары)

- туган тел почмагы (Г.Тукай портреты, аның әсәрләре җыентыгы, әсәрләр буенча ясалган д/у, татар халкының кул эше үрнәкләре, татар халкының милли әкиятләре

һ.б.); сд-проигрыватель, сд язмалар (әкиятләр, җырлар, бию көйләре, кул-бармак моторикасы гимнастикасы язмалары һ.б)

**Киенү - чишенү бүлмәсе.**

- физкультура почмагы (яшь үзенчәлекләренә яракланган материал: х/у маскалар, туплар, кыршаулар, сикергечләр һ.б., күргәзмә папкалар, уеннар фотоархивы):

- әти-әниләр өчен информацион-күргәзмә почмак ("Безнең тормыш", "Меню", "Котлыйбыз", "Көндәлек режим", "Турыдан-туры белем бирү эшчәнлегенең челтәре", "Табигать үзенчәлекләре", "Сезнең өчен әти-әниләр", "Белдерүләр")

- сәләмәтләндерү почмагы (чыныктыру һәм үз-үзеңә массаж ясау җиһазлары, массажерлар, кабыргалы такталар, пробка, төймә келәмчекләре һ.б., күргәзмә информацион материаллар.

**"Туган телдә сөйләшәбез" укыту–методик комплекты** Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 23.11. 2009/655 нче номерлы боерык нигезендә расланган "Мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасы структурасына федераль дәүләт таләпләре", Татарстан республикасының 2010-2015 елларга мәгариф системасын үстерү стратегиясе кысаларында балалар бакчаларында балаларга туган телне өйрәтүне, сөйләм үстерү, әдәби телдә сөйләшү күнекмәләре булдыру юнәлешен тормышка ашыру максатын күздә тотып төзелде. Ул түбәндәге бурычларны билгели:

- Балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү;
- Тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру;
- Бәйләнешле сөйләм үстерү;
- Тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.

ФГОС ка билгеләнгән "Танып белү - сөйләм үсеше юнәлешенә нигезләнеп, комплекслы - тематик план төзелде. Ул зурлар төркемендә 36 проектны, мәктәпкә әзерлек төркемендә 31 проектны һәм шул проектлар буенча төзелгән, зурлар төркемендә 98, мәктәпкә әзерлек төркемендә 100 эшчәнлек конспектларын үз эченә ала.

"Минем бакчам", "Мин яратам сине, Татарстан", "Саулык -зур байлык", "Исеменә күрә-җисеме", "Кунак булсаң - тыйнак бул", "Исәнме мәктәп", "Кояш системасы", "Дуслык белән көчле без", "Китап кайдан килә" һәм башка күп проектлар балалар һәм өлкәннәр тормышын чагылдыра, ана телен камил белергә, аның нечкәлекләренә төшенергә ярдәм итә, башка милләт халыклары белән дустанә мөнәсәбәттә яшәргә өйрәтә, экологик тәрбия күнекмәләре бирә, балаларда әхлакый сыйфатлар формалаштыра.

Бу укыту-методик комплектында ФГОС күрсәткән өч белем бирү өлкәсе карала:

**"Танып белү " белем бирү** өлкәсе балаларның туган як табигате, өлкәннәр хезмәте, ел фасыллары турындагы белемнәрен тирәнәйтүне, экологик

бәйләнешләрне күрә белү мөмкинлекләрен үстерүне  максат итеп куя. Шушы максатларны тормышка ашыруга ярдәм итүче  зурлар төркемендә 31 эшчәнлек, мәктәпкә әзерлек төркемендә  33 эшчәнлек  каралган. Балалар белән эшчәнлек сәяхәт, күзәтү, тәҗрибәләр уздыру, төрле уеннар формасында уздырыла.

**“Аралашу” белем бирү** өлкәсе  туган телнең нечкәлекләрен, тирәнлеген өйрәнү, сүзнең мәгънәсенә төшенү, логик фикерләү сәләтен үстерү, матур әдәбият әсәрләре белән кызыксыну, аваз культурасы, бәйләнешле һәм кара - каршы сөйләшә белү (диалогик сөйләм) күнекмәләрен камилләштерү, сәнгатьле сөйләмне үстерү бурычларын гамәлгә ашыра. Бу белем бирү  өлкәсенә туры килгән, зурлар төркемендә 35 эшчәнлек, мәктәпкә әзерлек төркемендә 36 эшчәнлек  тәкъдим ителә. Авазларны кабатлау,  калын һәм нечкә авазларның дифференцациясе һәр эшчәнлеккә өлеш итеп кертелде. Бу өлкәдәге эшчәнлек әңгәмә, үстерелешле диалог (балалар сорау бирә, сорауларга җавап кайтара),  сәхнәләштерү,  өстәл театры карау, рәсемнәр карау, алар буенча хикәя төзү, уен-викториналар; тасвирлау, үз тәҗрибәсеннән чыгып  хикәя төзү, хикәяне дәвам итеп сөйләү кебек эш формаларын күздә тота.

**“Матур әдәбият”белем бирү** өлкәсе  балаларыбызны мәрхәмәтле, әдәпле, инсафлы булырга өйрәтүче,  рухи сафлыкка,  хезмәт сөючәнлеккә, ярдәмчеллеккә өндәүче, яшь үзенчәлекләрен искә алып сайланган шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр белән таныштыруны,  әдәби телдә сөйләшергә өйрәтүне максат итеп куя.  Бу белем бирү өлкәсе зурлар төркемендә  32 эшчәнлекне, мәктәпкә әзерлек төркемендә 31 эшчәнлекне  үз эченә ала. Эшчәнлек матур әдәбият әсәрләрен уку, эчтәлеген сөйләү, ятлау кебек эш формаларын кулланып оештырыла.  .

Укыту-методик комплекты ФГОС та күрсәтелгән 10 белем бирү өлкәсе: (“Сәламәтлек”, “Физик культура”, “Социальләштерү”, “Хезмәт”, “Куркынычсызлык”, “Танып – белү”, “Аралашу”, “Матур әдәбият уку”, “Иҗат”, “Музыка”) буенча куелган бурычларны күздә тотып эшләнде Һәм алар турыдан-туры бердәм белем бирү эшчәнлеге  стуктурасында интегральләштереп  бирелде.

Укыту-методик комплектында тупланган материал балалар бакчасы педагогларына  балаларның сөйләмен үстерү, тирә - юнь, матур әдәбият әсәрләре белән таныштыру максатында гына түгел рәсем ясау, әвәләү, кул хезмәте, конструкцияләү, эксперимент эшләре, кисеп ябыштыру, музыка, физкультура эшчәнлекләрендә, иртән балаларны  кабул итү, саф һавада булу, табигатьне күзәтү вакытында, әти-әниләр белән бердәм эшчәнлектә иҗади якын килеп кулланылыр һәм ныгытылыр дип өметләнәбез.

## 1. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы турында гомуми мәгълүмәт

Зур Тигәнәле авылы муниципаль  мәктәпкәчә белем бирү оешмасы “Гомуми белем бирү, тәрбияләнүчеләрне интеллектуаль юнәлештә үстерү буенча   эшләүче   балалар бакчасы  1985 елның  сентяберендә ачылды.  Мәктәпкәчә оешмага 2-7 яшькә кадәр 16 бала йөри. Балалар бакчасында 1 төркем эшли.

Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмасы “Гомуми белем бирү балалар бакчасы тәрбияләнүчеләрне интеллектуаль юнәлештә үстерү буенча эшләүче (алга таба - мәктәпкәчә белем бирү оешмасы) түбәндәге документлар нигезендә эшли:

1. Рәсәй Федерациясенең 10.07.1992 №3266 - «мәгариф турында» законы.

2. Мәктәпкәчә белем бирүче оешмаларның типлаштырылган торыш карары (Рәсәй Федерациясенең 27.10.2011елда №2562 расланган карар).

3. Рәсәй Федерациясенең министрлыклар мәгарифыннан инструктив-методик хат № 65/23-16 14.03.00ел. «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның максималь йөкләнешкә гигиеник таләпләр”

4. Санпин 2.4.1.3049-13 «Үзгәреш №1 2.4.1. 2660-10 «Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында төзелешкә, эчтәлеккә һәм режим оешмасына карата санитар таләпләр” 15.05.2013 № 19342 Рәсәй Федерациясенең баш дәүләт санитария табибы белән 15.05.2013г №28564 расланган.

5. РФ фән һәм мәгарифлык министрлыгыннан хат 1.05.2007 №03-1213 «Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын бер төргә билгеләүче методик киңәшмәләр».

6. РФ фән һәм мәгарифлык министрлыгыннан боерык 3.11.2009 №655 «Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программаларында федераль дәүләт таләпләрен раслау».

7. РФ фән һәм мәгарифлык министрлыгыннан боерык 20.07.2011 №2151 «Мәктәпкәчә мәгарифлектә белем бирү программаларына федераль таләпләр раслау».

**2. Тәрбия һәм белем бирү процессының эчтәлеге**

Вакыт илебезнең мәгариф учреждениеләре эшенең яңа иҗтимагый-икътисади шартларда алып барылуы мәктәпкәчә мәгарифне заман таләпләренә туры китереп үзгәртүне, дәүләт һәм гаиләнең бала тәрбияләүдәге ролен яңа прогрессив формалар белән баетуны, һәр баланың эмоциональ иминлеге һәм төрле яклы үсеше өчен педагогик коллективның җаваплылыгын арттыруны таләп итә. Бүгенге мәктәпкәчә мәгарифнең приоритетлары үзгәрү сәбәпле балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программаларын яңартырга кирәкле булды. Мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләре, яңа заман таләпләрен исәпкә алып, башка концептуаль нигезендә төзелгән программалардагы мәсьәләләрне һәм эчтәлекне әлеге документка мөстәкыйль рәвештә кертәләр. Шулардан чыгып, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбия һәм белем процессында “Физик үсеш”, “Социаль-шәхси үсеш”, “Танып белү-сөйләм үсеше”, “Нәфис-нәфасәти үсеш” юнәлешләре булуы мөһим.

Зурлар төркеме өчен программа, 5 яшьтән 6 яшькә кадәр чорында тәрбия, белем бирү һәм үсешенең барлык төп юнәлешләрен чагылдыра. Белем бирү процессы “Туудан мәктәпкә кадәр” якынча балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы нигезендә төзелгән, Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева мөхәррияте астында, 2015 ел, 2-е басма, «Балалар бакчасы һәм гаилә өчен ана теле програмамсы» Ф.Ю. Юсупова, З.Ф. Камалова, Р.А.Борһанова, Мәгариф-2006;

«Гаиләдә, балалар бакчасында әдәплелек тәрбияләү программасы»

К.В. Закирова, Р.А. Низамов, Мәгариф-2006, “Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы”, Р.К.Шаехова, 2012. “Бергәләп үсәбез” программасы “Кроха” программасының (Г.Г. Григорьева, Н.П. Кочетова, Д.В. Сергеева һ.б.), “Школа 2000” Л.Г.Петерсонның эшчәнлек төрләренә нигезләнеп тулыландыра.

**3. Программаның төп максатлары:**

- һәр балалның сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында төрле яклы үсеш алуы турында кайгырту;

- балаларны аралашучан, игелекле, кызыксынучан, инициативлы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерү максатыннан чыгып, төркемнәрдә кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек атмосферасы тудыру;

- балалар эшчәнлеген төрле төрләрен киң куллану, укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан аларны интегральләштерү;

- тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештыру;

- балаларның мөмкин булганча төрле эшчәнлекләрен файдалану, белем бирү процессын нәтиҗәлерәк итү максатында аларны берләштерү;

- мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү оешмасы һәм гаилә шартларында бала тәрбиясенә якын килүгә юнәлеш бирү;

-гаиләнең балалар бакчасы төркемнәре һәм мәктәпкәчә оешманың тормышында катнашуын тәэмин итү;

- балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балага кирәклеген артык акыл һәм физик эш йөкләмәү максатыннан дәвамчынлыкны саклау;

- региональ якын килүне гамәлгә ашыру;

**Өлеш 1.**

**1.1. 3 -7 яшьлек балаларның психик үсешенең яшь үзенчәлекләре.**

Алтынчы яшьтәге балалар уен башлаганчы балалар рольләрне бүлешеп һәм эш-гамәлләрне яраклаштырып төзи беләләр. Уендагы мөнәсәбәтләр эчтәлек һәм интонация ягыннан алган рольгә туры килүче сөйләм белән үрелеп бара. Балаларның реаль мөнәсәбәтләре вакытындагы сөйләм рольдәге сөйләмнән аерыла. Балалар социаль мөнәсәбәтләрне үзләштерә һәм олыларның төрле эшчәнлекләрдәге буйсынучанлык позициясен аңлый башлыйлар. Уен тирәлеген оештырганда,мәгънәви яктан “үзәк” һәм “периферия” аерымлану күзәтелә (“Сырхауханә” уенында табиб кабинеты, ”Чәчтараш” уенында чәч кисү залы шундый үзәк, ә көтү залы уен тирәлегенең периферияс сыйфатында була). Балаларның уендагы эш-гамәлләре күптөрлеләнә.

Бу яшьтә балаларның сынлы сәнгать белән кызыксынулары аеруча көчәя. Алар бик еш рәсем ясый башлыйлар.

Балалар ел дәвамында 2 мең чамасы рәсем ясарга сәләтле. Рәсемнәр эчтәлекләре ягыннан бик күптөрле: аларда балаларның тормыштан алынган тәэсирләре дә, уйлап чыгарылган ситуацияләр дә, фильм һәм китапларга иллюстрацияләр дә чагылырга мөмкин.

Рәсем сюжетлы характер ала, күп тапкыр кабатланучы аз гына яки җитди үзгәрешләре булган сюжетлар бик еш очрый. Кеше сүрәте детальләштерелгән һәм пропорциональрәк була бара. Рәсем буенча, сүрәтләнгән кешенең җенесе һәм эмоциональ хәле турында әйтеп була.

Конструкцияләү бу эшчәнлек өчен шартларны анализлый белүләре белән характерлана. Балалар агач конструктор детальләрен кулланалар һәм атыйлар. Конструкцияләү эшчәнлеге схема нигезендә, үзләре уйлап яки шарт буенча эшкә ашырыла ала.

Балалар, берничә (2,4,6) тапкыр бөкләп, кәгазьдән, шулай ук табигый материаллардан конструкцияли алалар. Алар конструкцияләүнең 2 ысулын үзләштерәләр:

1)табигый материалдан сәнгати образ тудыру (бу очракта балалар, табигый материалларны төрле детальләр белән тулыландырып, бербөтен образ тудыралар); 2)сәнгати образдан чыгып табигый материал табу (бу очракта бала образны тудыру өчен кирәкле табигый материал сайлый).

Төсне, форма һәм зурлыкны, предметларның төзелешен аңлау, кабул итү камилләшә бара.

Балаларның күзаллаулары системалаштырыла. Балалар төп төсләр һәм аларның төсмерләрен генә түгел, ә арадаш төсләрнең төсмерләрен дә, шулай ук турыпочмак, овал, өчпочмакларның формаларын да аералар һәм атыйлар. Бер дистә предметны зурлыклары буенча рәткә төзеп куя алалар.

Зурлар төркемендә образлы фикер йөртү үсеше дәвам итә.

Балалар күрсәтмә планда мәсьәләне чишәргә генә түгел, хәтта объектны үзгәртергә, объектларның нинди эзлелектә бер-берсе белән бәйләнешкә керү мөмкинлекләрен күрсәтергә сәләтле. Ләкин болар бары тик балалар адекват фикерләү чараларын кулланган очракта гына дөрес булачак. Моннан тыш, логик сөйләмле фикерләүнең нигезе булган гомумиләштерү сәләте камилләшә бара. Объектлар төркемнәргә үзгәрергә мөмкин булган билгеләре буенча берләштереләләр.

Бу яшьтә уйлап чыгару сәләте үсү балаларга шактый оригиналь һәм эзлекле киңәйтелгән хикәяләр уйлап чыгарырга мөмкинлек бирә. Балаларның игътибар тотрыклылыгы үсә. Ирексез игътибардан аңлы игътибарга күчү күзәтелә.

Сөйләм, шул исәптән аның аваз ягы камилләшү дәвам итә. Балалар сызгырулы, чыжылдаулы һәм сонор авазларны дөрес әйтә башлыйлар. Шигырьләр укыганда, сюжетлы-рольле уеннар вакытында һәм көндәлек тормышта фонематик ишетү сәләте, сөйләмнең сәнгатьлелеге үсә, грамматик төзелеше камилләшә. Балалар барлык сүз

төркемнәрен кулланалар, сүз уйлап чыгару белән актив шөгыльләнәләр. Сүз байлыклары арта. Синоним белән антоним актив кулланылышка керә. Бәйләнешле сөйләм үсә. Балалар эчтәлекне дә, рәсемнәр буенча да иң мөһимен генә түгел, ә детальләрне дә кертеп сөйли ала башлыйлар.

Бу яшьнең казанышлары түбәндәгеләр белән характерлана: уен эшчәнлегендә рольләр бүлешү; уен пространствосын төзи белү; югары нәтиҗәлеге белән аерылып торган рәсем эшчәнлегенең алга таба үсеше; конструкцияләүдә үрнәкне карап гомумиләштерә белү. Зиһенгә алу объектларның катлаулы формаларын анализлау белән характерлана; фикерләү чараларын (схемалы, комплекслы кузаллаулар, цикллы үзгәрешләр турында кузаллаулар) үзләштерү белән бергә фикер йөртү сәләте үсә, гомумиләштерү күнекмәләре уйлап чыгару сәләте, тотрыклы игътибар, сөйләм, *Мин* образы үсә.

## *Якынча көндәлек режим*

| *Эшчәнлекнең төре* | ВАКЫТЫ |
|---|---|
| Балаларны кабул итү | 7.30 – 8.00 |
| Гигиена чаралары, иртәнге ашка хәзерлек, иртәнге аш. | 8.00 – 8.45 |
| Уеннар, ТББЭнә хәзерлек. | 8.45 – 9.00 |
| ТББЭ | 9.00 - 9.15 - 9.30 |
| Мөстәкыйль уеннар | 9.30 – 10.00 |
| Икенче иртәнге аш | 10.00 -10.20 |
| Урамга чыгуга хәзерлек | 10.20 – 10.30 |
| Саф һавага чыгу | 10.30 – 11.30 |
| Урамнан керү,гигиена чаралары,төшке ашка хәзерлек | 11.30 – 11.45 |
| Төшке аш | 11.45 – 12.20 |
| Гигиена чаралары, йокыга хәзерлек. | 12.20 – 12.30 |
| Көндезге йокы | 12.30 – 15.00 |
| Йокыдан уяну,чыныктыру чаралары. | 15.00 – 15.15 |
| Төштән соңгы аш. | 15.15 – 15.30 |
| Шәхси эш,аз хәрәкәтле уеннар, мөстәкыйль эшчәнлек. | 15.30 – 16.00 |
| Мөстәкыйль эшчәнлекләре,уеннар.Балаларны өйгә озату | 16.00 – 16.30 |

## *Җәйге чорга көндәлек режим*

| ***Эшчәнлекнең төре*** | ***Вакыты*** |
|---|---|
| Урамда:балаларны кабул итү, уеннар, иртәнге гимнастика | 7.30-8.20 |
| Иргәнге ашка хәзерлек,иртәнге аш | 8.20-8.55 |
| Уеннар, мөстәкыйль эшчәнлек, урамга чыгарга хәзерлек | 8.55-9.35 |
| Урамда:шөгылләр, уеннар, күзәтү, мөстәкыйль эшчәнлек, һава кояш процедуралары. | 9.35-11.15 |
| Урамнан керү, гигиена чаралары | 11.20-11.45 |
| Көндезге ашка хәзерлек, ашау вакыты | 11.45-12.20 |
| Йокларга эзерләнү, көндезге йокы | 12.20-15.00 |
| Йокыдан уяну,чыныктыру чаралары,төштән соңгы аш | 15.00-15.35 |
| Мөстәкыйль эшчәнлек, уеннар | 15.35-16.00 |
| Урамда, балаларны өйгә озату | 16.00-16.30 |

# 2022-2023 уку елына шөгыльләр челтәре

| **Көн** | **Шөгыль – зурлар төркеме** | **Вакыт** |
|---|---|---|
| **Дүшәмбе** | 1.Танып-белү белем бирү өлкәсе<br>2.Музыка<br>3.Рус теле | 9.05 - 9.30<br>9.35 - 10.00<br>15.25 - 15.50 |
| **Сишәмбе** | 1.Иң гади математик кузаллауларын үстерү<br>2.Физик культура<br>3.Рәсем | 9.05 - 9.30<br>9.35 - 10.00<br>15.25 - 15.50 |
| **Чәршәмбе** | 1.Аралашу<br>2.Музыка<br>3.Рәсем (кисеп ябыштыру) | 9.05 - 9.30<br>9.35 - 10.00<br>15.25 - 15.50 |
| **Пәнҗешәмбе** | 1.Матур әдәбият уку<br>2.Физик культура<br>3.Әвәләү (конструкцияләү) | 9.05 - 9.30<br>9.35 - 10.00<br>15.25 - 15.50 |
| **Җомга** | 1.Аралашу<br>2.Рус теле<br>3.Физик культура (саф һавада) | 9.05 - 9.30<br>15.25 - 15.50<br>10.10 - 10.35 |
| **Шимбә** | Хезмәт, мөстәкыйль уеннар | |

# Математикага перспектив план

АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Математика фәнендә иң мөһиме — математик бәйләнешләр һәм бәйлелекләрне дөрес тоемлап, логик фикерләргә өйрәтү.

Мәктәпкәчә яшьтәге бала фикерләвенең үсеше берничә этапта уза. Башта күрсәтмәле - нәтиҗәле фикерләү формалаша, ягъни бала аңындагы фикер үсеше ниндидер эшнең нәтиҗәсе, тәэсире аркылы барлыкка килә. Бу чор ахырында күрсәтмәле - образлы фикерләүгә нигез салына, ягъни бала образлар ярдәмендә фикерли башлый. Ә биш-алты яшьлек балада сөйләмле - логик фикерләү формалаша башлый, ул мантыйк үсешен һәм сүзләрне сөйләмдә нәтиҗәле куллануны үз эченә ала. Балалар мөстәкыйль фикерләргә, нәтиҗәләр ясарга, тиңләштерергә, чагыштырырга, анализларга, гади закончалыкларны кабул итәргә, аерым һәм уртак булган төшенчәләрне аңларга өйрәнә. Бала дөнья турындагы мәгълүматны аңлап һәм тирәнрәк итеп кабул итә башлый. Акыл эшчәнлегенең мантыйкый ысуллары - чагыштыру, гомумиләштерү, анализ, синтез, классларга аеру, серияләштеру, охшашлыклар табу, системалаштыру, абстрактлаштыру.

*Серияләштерү* - предметларны билгеле бер сыйфатлары буенча сайлап алып, аларны үсә бару йә кими бару тәртибендә урнаштыру.

Классик мисал: матрешкалар, пирамидалар, җыелмалы уенчыклар Һ.б.

*Анализ* - объектның үзлекләрен аерып чыгару, яки объектны төркемнән аеру, яки бер төркем объектларны билгеле бер үзлекләренә карап аеру.

*Синтез* - төрле элементларны (билге, үзлекләр) бөтенгә берләштерү.

*Чагыштыру* - ул объектның (предмет, күренеш, предметлар төркеме) охшашлыгын яки аермасын билгеләү буенча акыл эшчәнлегенең логик алымы. Баланың чагыштыру алымын тулысынча үзләштерүенең төп күрсәткече - олы кеше күрсәтмәләреннән башка гына аны куллана белүе.

*Классификацияләү* - күплекләрне билгеле бер билгеләре буенча төркемнәргә аеру. Күплек аз күплекләрдән тора. Бу аз күплекләр кисешмәскә һәм аларның уртак кыйммәтләре булмаска тиеш.

*Гомумиләштерү* - чагыштыру процессы нәтиҗәләрен сөйләм (вербаль) формасында оештыра белү. Мәктәпкәчә яшьтәге бала объектларны гомумиләштергәндә, аларның ике яки берничә уртак сыйфатын аерып чыгара. Мөстәкыйль эшчәнлек вакытында барлыкка килгән гомумиләштерү (болар - зур, болар - кечкенә; болар барысы - өчпочмаклар, ә болары - квадратлар һ.б.) бала тарафыннан нәтиҗәлерәк кабул ителә.

Балалар тәрбияче ярдәме белән унга кадәр санарга өйрәнәләр, саннарны урыннарына карап чагыштыралар, санның берәмлекләрдән торган составы белән танышалар, санның микъдари һәм тәртип мәгънәсен аңлый башлыйлар. Балалар исәпләргә, санап алырга, предметларның исәбен карточкаларга һәм рәсемнәргә карап белергә, хәрәкәт һәм авазлар буенча исәпләргә өйрәнәләр. Бөтен һәм өлешнең үзара

мөнәсәбәтләрен ачыклыйлар, вакыт һәм пространствода дөрес ориентлашырга өйрәнәләр.

Һәр яңа белемнәр алдан үзләштерелгәннәренә нигезләнеп башкарыла, дәресләр үзара системалы рәвештә бәйләнгән була.

Зурлар төркемендә атнага бер дәрес уздырыла (елына якынча 36 дәрес), дәреснең озынлыгы 25 минут.

## ПЕРСПЕКТИВ ПЛАНЛАШТЫРУ

СЕНТЯБРЬ

**Беренче дәрес**

Тема: **«Бер һәм ике, ике һәм өч саннарының барлыкка килүе һәм аларны чагыштыру. Иң биек, тәбәнәгрәк, иң тәбәнәк.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Балаларда математик үзлекләр һәм мөнәсәбәтләр турында күзаллауларны формалаштыруны дәвам итү. Ике һәм өч саннарының барлыкка килү юлларын искә төшерү. Бер һәм ике, ике һәм өч предметлары булган төркемнәрне аерырга өйрәтү, шуның нигезендә кайсы санның зуррак, кайсының кечерәк икәнлеген аңлату. Предметларны биш саны кысаларында санау күнекмәсен булдыру. Өч предметны аларның биеклегенә карап чагыштырырга өйрәтү: иң биек (тәбәнәк), биегрәк (тәбәнәгрәк);

2) Танып белүнең сенсор һәм логик мөмкинлекләрен үстерү, игътибарлылык, тәрбияче тарафыннан бирелгән биремнәрне үтәү осталыгын булдыру, мөстәкыйльлек сыйфатын тәрбияләү, сулыш күнегүләрен эшләү;

3) Мультфильм геройларына кызыксыну тәрбияләү, яшьтәшләре белән аралашу, бергәләп дәрестә катнашу теләген булдыру.

**Икенче дәрес**

Тема: **«Өч һәм дүрт саннарының барлыкка килүе һәм аларны чагыштыру. Озын, кыска, киң, тар.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Балаларга өч һәм дүрт саннарының барлыкка килүен, оешуын искә төшерү, предметларны санарга һәм санап алырга өйрәтү, предметларны озынлык, киңлек һәм калынлыкларына карап чагыштыру күнегүләрен үтәү;

2) Танып белүнең сенсор һәм логик ысулларын, дәлилле сөйләмне, игътибарлылыкны, мөстәкыйльлекне үстерү;

3) Математика дәресләренә кызыксыну тәрбияләү.

**Өченче дәрес**

Тема: **«Геометрик фигуралар. Өч һәм дүрт саннарының оешуы. Кычкырып санау.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Төрле геометрик фигураларны аерырга өйрәтү: овал, квадрат, өчпочмак, турыпочмаклык, шар, цилиндр, куб; фигураларны, күреп тоемлана торган үрнәк аркылы, капшап табарга өйрәтү; балаларда өч һәм дүрт саннарының оешуы турындагы күзаллауны ныгыту; тавышлар һәм предметлар саны арасында бәйләнеш урнаштырырга өйрәтүне дәвам итү;

2) Игътибарны, сөйләмне, күреп күзаллауны үстерү;

3) Математика дәресләренә кызыксыну тәрбияләү.

**Дүртенче дәрес**

Тема: **«Предметларны биш саны чикләрендә санау. Түгәрәк, квадрат, турыпочмаклык. Кәгазь битендә ориентлашу: өстә, аста, сулда, унда, уртада. Үз-үзеңнән юнәлеш: алда, артта.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Биш саны чикләрендә санау күнекмәләрен ныгыту; берьюлы ике санны, предмет атамаларын һәм аларның урнашу урыннарын истә калдыру күнегүләрен үтәү. Түгәрәкне, квадратны, турыпочмаклыкны аеру осталыгын ныгыту. Аларны бербирсенә туры китереп кәгазь битендә урнаштыру, аста, өстә, сулда, уңда, уртада сүзләрен кулланып, фигураларның төрлечә урнашуларын билгеләү. Предметларны үз-үзеңнән төрле юнәлештә урнашканлыгын билгеләргә өйрәтү: алда, артта һ.б.;

2) Игътибарлылык, сөйләм, логик фикерләү, күреп танып белүне үстерү. Тәрбияче әйткән биремнәрне дөрес итеп, тырышып башкарырга өйрәтү;

3) Юл йөрү кагыйдәләренә карата кызыксыну тәрбияләү, пөхтәлеккә игътибарны арттыру.

ОКТЯБРЬ

**Бишенче дәрес**

Тема: **«Овал. Предметларны аларның үлчәмнәре арта һәм кими бару тәртибендә урнаштыру (тәртипкә китерү).»**

**Программ эчтәлек:**

1) Балаларны овал белән таныштыру; түгәрәк һәм овалны аеру күнекмәләрен белдерү; предметларны санау күнекмәләрен дәвам итү; предметларны аларның үлчәмнәре арта

бару һәм кими бару тәртибендә урнаштыру; «иң зур», «кечерәк», «тагын да кечкенә», «әз генә кечкенә», «иң кечкенә» сүзләрен кулланырга өйрәтү; предметларны капшап санарга өйрәтү;

2) Логик фикерләү, сенсор танып белү ысулларын үстерү – тәртип белән урнаштыру, күзаллау;

3) Математика фәненә ихтирам тәрбияләү, балаларның иҗади кызыксынуын үстерү.

**Алтынчы дәрес**

Тема: **«Алты һәм җиде саннарының оешуы. Яссылыктагы юнәлеш: сулдан, уңнан, уртадан.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Биш, алты һәм җиде саннарының оешуын күрсәтү; балаларны җиде саны чигендә хисапларга өйрәтү; предметларның санын хәтердә калдыруны ныгыту; яссылыкта юнәлеш табарга өйрәтү: сулдан, уңнан, уртадан; балаларны урынны билгеләүдә күнектерү: алда, артта, сулда, уңда, алдында, артында;

2) Мөстәкыйльлекне, күзаллауны үстерү;

3) Балалар арасында дустанә мөнәсәбәтләрне, бер-береңә хәбәр итеп шөгыльләнүне тәрбияләү.

**Җиденче дәрес**

Тема: **«Алты һәм җиде саннарының оешуы. Предметларны җиде саны эчендә санау. Яссылыкта ориентлашу.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Алты һәм җиде саннарының оешуы һәм предметларны җиде эчендә санау турындагы белемнәрне ныгыту; яссылыкта ориентлашу, предметларның таблицада эзлекле урнашуы күнекмәләрен ныгыту, предметларның пространствода урнашу тәртипләрен дөрес итеп атау: уртада (үзәктә), өстә, аста, сулда, уңда;

2) Балаларда интеллектуаль-иҗади башлангычларны үстерү: зирәклек, мисалларның стандарт булмаган чишелешен табарга омтылу, аң операцияләре, математик үзлекләрне һәм чагыштырмаларны танып белүнең логик ысуллары: чагыштыру һәм анализ, логик фикерләү, комбинатор сәләтләр;

3) Коллективта эшләү һәм шөгыльләнү теләген тәрбияләү; мәктәпкәчә яшьтәге балаларның гамәли эшчәнлегендә иҗади мөстәкыйльлекнең күренүе өчен шартлар тудыру.

**Сигезенче дәрес**

Тема: **«Тавышларны санау. Тәүлек өлешләре. Атна көннәре. Кәгазь битендә ориентлашу.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Тәүлек өлешләре турындагы күзаллауны ныгыту, җиде көннең (тәүлекнең) атна төзүен, атнаның һәр көне үз исеме белән йөрүен, җиде көннең һәрвакыт бер тәртиптә килүе турындагы күзаллауны балаларга ирештерү; кычкырып санарга өйрәтү, тавыш саны һәм күз белән кабул ителгән предметларның саны арасында бәйләнеш урнаштыру күнекмәсен формалаштыру; геометрик фигуралар турындагы белемнәрне һәм кәгазь битендә ориентлашуны ныгыту;

2) Танып белүнең сенсор һәм логик ысулларын, дәлилле сөйләмне, игътибарлылыкны, мөстәкыйльлекне, тембр тавышын үстерү;

3) Яшьтәшләрең белән бергәләп эшләү теләген тәрбияләү.

НОЯБРЬ

**Тугызынчы дәрес**

Тема**: «Сигез санының оешуы. Сигезгә кадәр санау. Форма.»**

**Программ эчтәлек**:

1) Балаларны сигез санының оешуы белән таныштыру һәм аларны сигезгә кадәр санарга өйрәтү; төрле зурлыктагы предметларның саны тигезлеген һәм тигез түгеллеген күрә белергә өйрәтү; төрле геометрик фигуралар төзергә өйрәтү осталыгын формалаштыру, зурлык турындагы күзаллауны төгәлләштерү;

2) Танып белүнең сенсор һәм логик ысулларын үстерү: тикшерү, каршы кую, анализ, чагыштыру, абстрактлаштыру, сөйләм, зирәклек, тапкырлык;

3) Физкультура белән шөгыльләнәсе килү теләген, балалар арасында дуслык мөнәсәбәтләрен тәрбияләү.

**Унынчы дәрес**

Тема: **«Сигез саны. Озынлык, биеклек.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Балаларда сигез саны турындагы күзаллауны барлыкка китерү һәм сигез санына кадәр саный белү күнекмәләрен ныгыту. Бер төркем предметларны икенче төркемдәге предметлар белән чагыштырып карап, аларның кайсында предметларның күбрәк (әзрәк) булуын ачыкларга өйрәтү; предметларның озынлыкларын һәм биеклекләрен билгеләү; билгеләнгән сан буенча хәрәкәтләр үтәү;

2) Логик фикерләү, хәтер һәм күзаллый белү күнекмәләрен үстерү;

3) Мөстәкыйльлек һәм дөрес итеп тыңлый белүне тәрбияләү.

**Унберенче дәрес**

Тема: **«Тугыз санының барлыкка килүе. Предметлар санының алар арасындагы ераклыкка бәйле булмавы. Озынлык. Кальгалык.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Балаларны тугыз санының барлыкка килүе һәм оешуы белән таныштыру, тугыз саны кысаларында санарга өйрәтү; предметлар санының алар арасындагы ераклыкка бәйле түгеллеген аңлату; предметларның биеклеге һәм калынлыгына карап, аларны үзара чагыштыру; предметларны биеклеге һәм калынлыгы үсә (кими) бару тәртибендә дөресләп тезәргә өйрәтү; чагыштыру төренә карап, предметларны төрлечә урнаштыру мөмкинлеге барлыгын күрсәтү;

2) Игътибарлылыкны, хәтерне, логик фикерләүне, күзаллауны үстерү;

3) Мөстәкыйльлекне, тыңлый белү сыйфатын тәрбияләү.

**Уникенче дәрес**

Тема: **«Тугыз санының оешуы. Биеклек, калынлык.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Балаларда тугыз санының оешуы турында күзаллауны һәм тугыз саны чигендә санау күнекмәләрен ныгыту; ишетеп Һәм хәрәкәт нигезендә санауны күнектерү; предметларны биеклек Һәм калынлык буенча чагыштыру осталыгын формалаштыруны дәвам итү; аларны биеклеге һәм калынлыгы кимү (арту) тәртибендә рәткә салырга өйрәтү;

2) Логик фикерләүне, игътибарны, хәтерне һәм күзаллауны үстерү;

3) Мөстәкыйльлекне, тыңлый белү осталыгын, башкалар белән дуслашырга теләү хисен тәрбияләү.

ДЕКАБРЬ

**Унөченче дәрес**

Тема: **«Предметларны терле юнәлештә санау. Предметларны бирелгән сан буенча исәпләү. Кәгазь битендә ориентлашу. Озынлык һәм калынлык.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Исәпне төрле юнәлештә алып барып булганлыгын аңлату: сулдан уңга, уңнан сулга, өстән аска, астан өскә; предметларны тугыз саны кысаларында бирелгән сан буенча санарга өйрәтү; предметларның саны һәм аларның пространствода урнашулары арасындагы бәйләнешне аңлату; предметларның озынлыклары һәм калынлыклары үзгәрүне күрергә өйрәтү һәм балаларның үзләренә дә бу сыйфатларны үзгәртү буенча күнекмәләр эшләтү;

2) Танып белүнең сенсор һәм логик ысулларын, диалог сөйләм, игътибарлылык, педагогның биремнәрен үти белү осталыгын, мөстә-кыйльлекне, кулларның вак моторикасын үстерү;

3) Яшьтәшләре белән берлектә дәрестә шөгыльләнүгә кызыксыну уяту.

**Ундүртенче дәрес**

Тема: **«Ун саны. Предметларны ун саны кысаларында санау. Озынлык буенча чагыштыру.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Балаларда ун саны турындагы күзаллауны барлыкка китерү һәм унга кадәр саный белү күнекмәләрен ныгыту; саннарны исемнәр белән килеш һәм санда килештереп санау. Бер үк төрле озынлыктагы предметларны сайлап алырга өйрәнү; парлы предметларның озынлыкларын чагыштыру; озын, кыска, озынрак, кыскарак, иң озын, тигез озынлыкта сүз тезмәләрен балалар сөйләмендә активлаштыру;

2) Игътибарлылыкны, күреп танып белүне, логик фикерләүне, күзаллауны, сөйләмне үстерү;

3) Мөстәкыйльлек, тырышлык, белем алуга кызыксыну, башкаларга ярдәм итү теләген тәрбияләү.

**Унбишенче дәрес**

Тема: **«Унга кадәр санау. Шартлы предмет моделе. Геометрик фигуралар.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Исәпне төрле юнәлештә алып бару күнекмәләрен үстерү. Төрлечә урнашкан предметларны санарга өйрәтү. Ун санының барлыкка килүе турындагы белемнәрне ныгыту, унга кадәр санау. Шартлы предмет модельләре белән эшләү осталыгын формалаштыру, геометрик фигуралар - өчпочмак һәм турыпочмаклыкның якларының озынлыкларына бәйле рәвештә төрле булуларын күрсәтү;

2) Сөйләм, игътибарлылык, логик фикерләүне (чагыштыру, анализ, абстракцияләү) үстерү;

3) Тырышлыкка омтылышны үстерү, башлаган эшне ахырына кадәр җиткерүнең кирәклеген аңлату.

**Уналтынчы дәрес**

Тема: **«Предметлар санының урнашу рәвешенә бәйсез булуы.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Балаларга предметларның саны аларның урнашу рәвешенә бәйсез булуын искә төшерү; төрлечә урнашкан төркемнәрдә предметлар санының тигез икәнен күрергә өйрәтү; предметларны киңлек, озынлык буенча чагыштыру;

2) Күрсәтмә - образлы фикерләүне, игътибарлылыкны, күреп хәтердә калдыруны, күзаллауны, диалогик сөйләмне үстерү;

3) Математика дәресләренә карата кызыксынуны үстерү, авыр хәлдә калганнарга ярдәм итәргә кирәклеген аңлату.

ГЫЙНВАР

**Унҗиденче дәрес**

Тема: **«Ишетеп санау. Предметларның озынлыгы һәм киңлегенә карап, аларны чагыштыру.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Предметларның озынлыгы һәм киңлегенә карап, аларны чагыштырырга өйрәтү; күзләрне йомган килеш, кул чабуларны ишетеп санау; төрлечә урнашкан предметларны санарга өйрәтү;

2) Танып белүнең сенсор һәм логик ысулларын, игътибарлылыкны, сөйләмне, иҗади күзаллауны үстерү;

3) Бердәмлек, бер-береңә ярдәм итәсе килү сыйфатын тәрбияләү.

**Унсигезенче дәрес**

Тема: **«Атна көннәренең эзлеклелеге. Кәгазь яссылыгында ориентлашу.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Атна көннәренең эзлеклелегенә төгәллек кертү; балаларны кәгазь яссылыгында ориентлашырга күнектерү; кәгазьнең өске, аскы, уң, сул кырыйларын, өске уң һәм сул, аскы уң һәм сул почмакларын табу; күрсәтелгән предметлар санын кәгазь битенең билгеле бер өлешендә тупларга, ничә, нинди предмет һәм аларны кая куярга кирәклеген өйрәтү; биш саны эчендә санау осталыгын ныгыту;

2) Сөйләмне, күзаллауны, логик һәм образлы фикерләүне үстерү;

3) Бәйрәмнәргә кызыксынуны, вакыт белән бәйле рәвештә үз эшчәнлегеңне оештырырга омтылуны тәрбияләү.

**Унтугызынчы дәрес**

Тема: **«Шартлы үлчәм белән предметның буен һәм иңен үлчәү. Кәгазь битендә ориентлашу.»**

**Програм эчтәлек:**

1) Балаларны предметларның буен һәм иңен шартлы үлчәү алымы белән таныштыру. Кәгазь яссылыгында ориентлашу буенча күнегү уздыру. Кайда һәм күпме геометрик фигура урнаштырырга кирәклеген өйрәтү һәм шул билгеләнгән тәртипне истә калдыру буенча махсус күнегүләр башкару. Исәпләү күнекмәләрен арттыру;

2) Игътибарлылык, логик фикерләү һәм хәтерне үстерү;

3) Пөхтәлек, ярдәмчеллек, кунакчыллык тәрбияләү.

**Егерменче дәрес**

Тема: **«Квадрат һәм турыпочмаклык. Кәгазь бите яссылыгында ориентлашу. Предметларны капшап санау.»**

**Програм эчтәлек:**

1) Квадрат һәм турыпочмаклыкны аеру осталыгын формалаштыру, аларның охшашлыгын һәм аермалы якларын табарга өйрәтү: икесенең дә дүрт ягы һәм дүрт почмагы бар; якларының озынлыкларын күрсәтү (квадратның яклары үзара тигез, турыпочмаклыкның капма-каршы яклары гына үзара тигез), кәгазь яссылыгында күнегүләр ясау. Кәгазьнең сул, уң һәм өстәге, астагы почмакларын, шулай ук сул, уң, өс һәм ас якларын табарга өйрәтү. Предметларны капшап карап санау күнегүләрен үтәү. Биремне истә калдыру, аны кабатларга өйрәтү. Нәтиҗәләрне үрнәк белән чагыштыру, ябыштыру күнекмәләрен ныгыту;

2) Балаларның аңында форма һәм пространство турындагы күзаллауларны, реакция тизлеген үстерү. Бирелгән биремне беренче тапкырдан ук ишетү һәм аңлау сыйфатын тәрбияләү;

3) Пөхтә булу серләренә төшендерү.

ФЕВРАЛЬ

**Егерме беренче дәрес**

Тема: **«Геометрик фигуралар (турыпочмаклык, квадрат.) Предметларның унда һәм сулда урнашуы.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Турыпочмаклык һәм квадратны аеру күнекмәләрен формалаштыруны дәвам итү, квадрат һәм турыпочмаклыкның төп сыйфатлары турында күзаллауларны ныгыту; билгеләнгән юнәлештә хәрәкәт итү һәм адымнарны санау; төрле өлешләрдән торган предметларның формаларын тәртип буенча тикшереп өйрәнү; уку-укыту эшчәнлегенә ияләшү: олы кеше эндәшкәч, берәм-берәм җавап бирергә өйрәнү, башка балаларны тыңларга, аларның җавапларын тулыландырырга, уен кагыйдәләрен бозмыйча уйнарга өйрәнү;

2) Күрсәтмә-образлы һәм сөйләм-логик фикерләүне үстерү, игътибарлылык, иҗади мөмкинлекләр, дөрес итеп сөйләргә һәм тыңларга өйрәтү, аермалыклар һәм уртак сыйфатларны табу күнекмәләрен булдыру һәм аларны сөйләмдә белдерергә өйрәтү;

3) Пөхтәлек һәм чисталыкка омтылыш булдыру.

**Егерме икенче дәрес**

Тема: **«Предметларны үрнәк һәм әйтелгән сан буенча санау.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Балаларда төрле предметларның тигез санын күрү һәм аны сөйләмдә чагылдыру осталыгын формалаштыру: бишәр, алтышар предмет һ. б.; билгеле бер сандагы предметларны үрнәк һәм әйтелгән сан буенча санап чыгу осталыгын ныгыту; төрле предметларның тигез санын билгеләү өчен өстәмә (кушымта) алымыннан куллану, уң кул белән сулдан уңга таба хәрәкәт итеп, предметларны рәтләр буенча, берсе өстенә берсен урнаштыру;

2) Күзләр координациясе хәрәкәтен, кулларның вак моторикасын, тавыш көчен һәм тембрын үстерү;

3) Хезмәт сөючән һәм түземле булу омтылышын тәрбияләү.

**Егерме өченче дәрес**

Тема: **«Предметларны озынлык һәм биеклек буенча чагыштыру.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Төрле предметларның тигез санда икәнен һәм аны сөйләмдә чагылдыру осталыгын ныгыту; санарга тиешле предметларның санын хәтердә калдырырга өйрәтү; тигез - күбрәк - азрак алымы белән куллануны ныгыту; предметларны өч рәткә, берсе астына

берсен тигез итеп кую; төрле озынлыктагы һәм биеклектәге предметларны чагыштырырга һәм төрле төрдәге зурлыклар арасында бәйләнеш урнаштырырга өйрәтү; «иң озын», «иң кыска», «озынрак», «кыскарак», «биегрәк, «тәбәнәгрәк» сүзләрен һәм гыйбарәләрен кертеп, балаларның сүзлек составын активлаштыру;

2) Игътибарны, сөйләмне, фикер йөртеп чагыштыруны һәм анализны, иҗади сәләтне үстерү;

3) Дәресне ярату, табигатькә сак мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Егерме дүртенче дәрес**

Тема: **«Төрле предметларның тигез санын исәпләү. Төрлечә урнаштырылган предметларны санау. Предметларны капшап санау.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Төрле предметларның тигез санын күрү, предметларны уң кул белән сулдан уңга дөрес итеп санау һәм берсе астына берсен төгәл итеп урнаштыру, төркемнәрдәге предметларның тигез санын сөйләмдә чагылдыру осталыгын ныгыту; төрлечә урнаштырылган предметларны санау күнекмәләрен ныгыту;

2) Сөйләмне, игътибарны, танып белүнең сенсор, логик ысулларын үстерү;

3) Дөрескә кызыксыну, бер-береңне сөендерү теләге тәрбияләү.

## МАРТ

**Егерме бишенче дәрес**

Тема: **«Тавышларның саны һәм предметларны санап чыгу» Шар, куб, цилиндр. Алда, артта.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Балаларны бер үк вакытта тавышларны һәм предметларны санарга өйрәтү; отып алынган тавышлар һәм саналган предметлар саны арасында бәйләнеш урнаштыру. Балаларда шар, куб, цилиндр турындагы күзаллауны, зур һәм кечкенә үрнәктәге фигуралар эшләүне ныгыту; балаларны объектның алдында һәм артында урын табарга өйрәтү;

2) Игътибарны, сөйләмне, фикер йөртеп чагыштыруны һәм анализны, пространствода юнәлеш табу осталыгын үстерү;

3) Балаларда дәрес каһарманнары кичергән хисләрне уртаклашу осталыгын, оешканлык, бердәмлек, бер-береңә ярдәм итү сыйфатларын тәрбияләү.

**Егерме алтынчы дәрес**

Тема: **«Предметларны берничә өлешкә бүлү. Кычкырып санау, хәрәкәтләрне санау.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Бөтен бер предметны тигез ике өлешкә һәм дүрт өлешкә бөкләп бүлергә өйрәтү; бүлү нәтиҗәләрен сөйләмдә белдерергә өйрәтү (уртага бөкләдек, ике (дүрт) тигез өлеш барлыкка килде, бөтеннең яртысы, икедән бер өлеш, дүрттән бер өлеш); бөтенне ике тигез өлешкә бүлүдән аның яртысы барлыкка килүен аңлату; кычкырып санау буенча күнегүләрне үтәү, хәрәкәтләрне санарга өйрәтү; саннар турындагы белемнәрне ныгыту;

2) Игътибарлылыкны, сөйләмне, логик фикерләүне, зирәклекне, күреп хәтердә калдыруны, күзаллауны үстерү;

3) Тырышлык, дәрестә шөгыльләнү теләген, тыңлый белү сыйфатын тәрбияләү.

**Егерме җиденче дәрес**

Тема: **«Бөтеннең ике һәм дүрт тигез кисәккә бүленүе. Объекттан сулда һәм уңда урын табу.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Балаларда, кушу юлы белән, бөтенне ике һәм дүрт тигез кисәккә бүлүне ныгыту; ярты дип ике тигез кисәкнең берсен атау күзаллавын ныгыту; квадратны һәм турыпочмаклыкны төрле ысуллар белән тигез кисәкләргә бүлгән вакытта нинди формалар барлыкка килүен билгеләргә өйрәтү; объекттан сулда һәм уңда урын табарга өйрәнү;

2) Балалар сөйләмендә түбәндәге сүзләрне һәм гыйбарәләрне активлаштыру: урталай, ике (дүрт) тигез кисәк, ике (дүрт) кисәкнең берсе; мәгънә ягыннан капма-каршы сүзләр;

3) Дуслык һәм ярдәмчеллек хисләре тәрбияләү өчен шартлар тудыру.

**Егерме сигезенче дәрес**

Тема: **«Ике һәм дүрт саннарының берәмлекләрдән торган составы. Предметларны бөкләп, һәм кисеп, ике тигез өлешкә бүлү.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Ике һәм дүрт саннарының берәмлектән торган микъдари составы турында күзаллау формалаштыру; предметларны бөкләп Һәм кисеп ике тигез өлешкә бүлү буенча күнегү башкару; бөтеннең өлештән зуррак, ә өлешнең бөтеннән кечерәк булуы турындагы белемнәрне ныгыту. Тәртип буенча исәпләү күнекмәләрен ныгыту; санны хәрәкәт исәбе белән тәңгәлләштерергә өйрәтү;

2) Чагыштыру, анализны аңда башкару операцияләрен үстерү, иҗади мөмкинлекләрне, игътибарлылык, сөйләм үсешен ныгытуга ирешү;

3) Дәресләрдә шөгыльләнү теләген, бер-берең турында кайгырту сыйфатын, киң күңеллелек тәрбияләү.

АПРЕЛЬ

**Егерме тугызынчы дәрес**

Тема: **«Санның берәмлектән торган микъдар составы. Бөтенне ике һәм дүрт өлешкә бүлү.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Бишкә кадәр булган саннарның берәмлектән торган микъдари составы белән таныштыруны дәвам итү; балаларны предметларны үзара тигез булган ике һәм дүрт өлешкә бөкләү һәм кисү юлы белән бүлергә өйрәтү; бөтен һәм аның өлеше арасында булган бәйләнешне ачыклау;

2) сөйләмне, игътибарлылыкны, күзаллауны, танып белүнең сенсор һәм логик ысулларын үстерү;

3) дәресләргә булган кызыксынуны, башкаларны сөендерәсе килү теләген тәрбияләү.

**Утызынчы дәрес**

Тема: **«Тәртип буенча җидегә кадәр санау. Санның берәмлекләрдән торган составы (биш саны).»**

**Программ эчтәлек:**

1) Тәртип саннарының мәгънәсен ачу һәм җидегә кадәр тәртип буенча санауның күнекмәләрен бирү; башка предметлар арасында предметның тәртип урынын билгеләгәндә, санау юнәлешенең әһәмиятен күрсәтү; санның берәмлекләрдән торган составы турында биш санына кадәр булган күзаллауны үстерүне дәвам итү;

2) Танып белүнең сенсор һәм логик ысулларын үстерү: тәртипкә салу, синтез, анализ, абстрактлаштыру, диалогик сөйләм, музыкаль ишетү сәләте;

3) Бер-береңә игътибарлы мөнәсәбәт, хөрмәт, эстетик зәвык тәрбияләү.

**Утыз беренче дәрес**

Тема: **«Атна көннәре. Чиктәш саннарны чагыштыру. Предметларны ун саны эчендә санарга һәм башлап санарга күнектерү. Геометрик фигура модельләреннән предметлар төзү.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Балаларның атна көннәре турындагы күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү: һәр көн атамасын тәртип саны һәм балалар эшчәнлегенең төгәл эчтәлеге белән бәйләргә өйрәтү; күрсәтмә материалга таянып, чиктәш саннарны чагыштырырга өйрәтү: биш һәм алты, алты һәм җиде; предметларны ун саны эчендә санарга һәм башлап санарга күнектерү; геометрик фигура модельләреннән төзелгән катлаулы формадагы предметларны анализларга һәм яңадан торгызырга өйрәтү;

2) Балаларда интеллектуаль-иҗади башлангычларны үстерү: тапкырлык, зиһенлелек, зирәклек;

3) Кыенлыкларны җиңгәндә, үз дигәнеңдә нык торучанлыкны тәрбияләү.

**Утыз икенче дәрес**

Тема: **«Чиктәш саннарны чагыштыру. Озынлык буенча ун предмет арасында бәйләнеш урнаштыру.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Чиктәш саннарны күрсәтмә материалга нигезләнеп чагыштыру күнекмәләрен формалаштыру (өч һәм дүрт; дүрт һәм биш); озынлык буенча ун предмет арасында бәйләнеш урнаштырырга күнектерү; кагыйдә нигезендә предметларны озынлыклары кимү тәртибендә бер рәткә тезәргә өйрәтү; атна көннәре турындагы мәгълүматны ныгыту;

2) Күрү хәтерен, кулларның вак моторикасын, сөйләмне, игътибарны, танып белүнең логик ысулларын — чагыштыру һәм анализны үстерү;

3) Тырыш булу, башлаган эшне ахырына кадәр җиткерү омтылышын тәрбияләү.

МАЙ

**Утыз өченче дәрес**

Тема**: «Чиктәш саннарны чагыштыру. Предметлар санының аларның зурлыгыннан бәйсез булуы. Түгәрәк, турыпочмаклык, квадрат, өчпочмак.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Бер-берсеннән бер элементка зуррак яки кечерәк булган күплекне күзаллау осталыгын формалаштыру; бер-берсеннән кайсы санның зуррак яки кечерәк булуын сөйләмдә дөрес итеп чагылдыру; балаларны саннарны чагыштырырга һәм ике чиктәш санның кайсысы бер-берсеннән зуррак яки кечерәк булуын билгеләргә өйрәтү (алты һәм җиде саннары белән); рәсемдә сурәтләнгән формаларны геометрик фигуралар белән чагыштырырга өйрәтү; предметлар санының аларның зурлыгыннан бәйсез булуын күзаллауны ныгыту;

2) Үзара тикшерү күнекмәләрен, зиһенлелекне, күрү хәтерен, күз алдына китерүне, сөйләмне, конструктив осталыкларны үстерү;

3) Мөстәкыйльлек, тырышлык, игътибар белән тыңлый белү, математика дәресләренә кызыксыну тәрбияләү.

**Утыз дүртенче дәрес**

Тема: **«Алты һәм җиде, җиде һәм сигез саннарын чагыштыру.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Балаларны саннарны чагыштырырга һәм ике катнаш санның кайсы һәм күпмегә бер-берсеннән зуррак яки кимрәк булуын (алты һәм җиде, җиде һәм сигез) билгеләргә өйрәтү; анализаторлар ярдәмендә санау күнекмәләрен үстерү; берсендә икенчесенә караганда бер элементка күбрәк яки азрак булган төркемнәр ясау; предметларның саны аларның зурлыгына (үлчәменә) бәйле булмавы турындагы күзаллауны ныгыту; карточкаларда сурәтләнгән  формалар белән геометрик фигураларны чагыштырырга өйрәтү;

2) Балаларның игътибарын, хәтерен, логик һәм иҗади сәләтләрен үстерү;

3) Үзконтроль, үзанализ күнекмәләрен тәрбияләү.

**Утыз бишенче дәрес**

Тема: **«Җиде һәм сигез, сигез һәм тугыз, тугыз һәм ун саннарын чагыштыру. Бармаклар белән капшап исәпләү. Предметлар санының алар арасындагы ераклыктан бәйсезлеге. Биеклек буенча тәртипкә салу.»**

**Программ эчтәлек:**

1) Балаларны саннарны чагыштырырга, ике санның кайсысы һәм күпмегә зуррак яки кечерәк булуын билгеләргә өйрәтү (җиде һәм сигез, сигез һәм тугыз, тугыз һәм ун саннары мисалында); бер-берсеннән бер предметка артык яки ким күплекләр җыелмасын күзалларга өйрәтү; предметларны тавыш буенча һәм капшап карап санарга күнектерү; предметларның саны аларның урнашу рәвешенә бәйсез булуын ныгыту; зурлыкларның тәртип белән урнашуы турындагы күзаллауны формалаштыру; өч предметның үлчәмнәрен үзара чагыштыру буенча күнекмәләр булдыру;

2) Танып белү процессларын, гомуми һәм вак моториканы үстерү;

3) Педагог һәм яшьтәшләре белән дусларча бәйләнеш тәрбияләү.

**Утыз алтынчы дәрес**

Тема: **«Саннарның эзлеклелеге. Чиктәш саннарны чагыштыру. Тәртип буенча санау. Санау таякчыкларыннан геометрик фигуралар ясау.»**

**Програм эчтәлек:**

1) Саннарның билгеле бер эзлеклелеге турында күзаллауны формалаштыру; биш саны эчендә һәм тәртип буенча санауда чиктәш саннарны чагыштыруны күнектерү; санау таякчыклары белән белемнәрне ныгыту (кәгазь тасмалардан), санның берәмлекләрдән торган составы, геометрик фигуралар;

2) Игътибарны, сөйләмне, куелган бурычны һәм аңа ирешү ысулларын аңлый белүне, куллар хәрәкәте координациясен үстерү;

3) Балалар арасында дуслык мөнәсәбәтләрен, тырышлыкны, бергәләшеп уйнау һәм эшләү тәртибен тәрбияләү.

## СУРӘТЛӘҮ ҺӘМ КОРУ ЭШЧӘНЛЕГЕ өчен перспектив планлаштыру

Аңлатма язуы

Базар реформалары җәмгыятьне яңа формациягә этәрде. Мәгариф реформасы белем бирү максатын үзгәртте. Элек безнең максат һәрьяктан үскән шәхес тәрбияләүдән гыйбарәт булса, хәзер исә шәхес компетентлы һәм тирәлек шартларына яраклашкан булырга тиеш.

Татарстан Республикасы - Россия Федерациясенең күпмилләтле төбәкләреннән берсе. Дәүләт сәясәтенең мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендәге төп бурычы мәктәпкәчә белем бирүнең нәтиҗәлелеген күтәрүдән һәм балаларга аңлаешлы булуын тәэмин итүдән гыйбарәт. ТРның «Мәгариф турында»гы Законында уку-укыту, белем бирүнең гуманистик, үсешкә этәрүче, милли характерда булуын тәэмин итү зарурлыгы, тәрбия һәм белем биргәндә тормыш һәм милли-мәдәни традицияләр белән бәйләнешнең әһәмиятлелеге алга сөрелә.

Әлеге максат шулай ук сәнгати белем һәм тәрбия бурычлары аша да гамәлгә ашырыла. Алар балаларның образлы, иҗади фикер йөртүен, күзаллавын, нәфасәти (эстетик) хисләрен, кыйммәтләр критерийларын үстерүгә, халык иҗат мирасы үрнәкләре белән таныштыруга, белем алу барышында практик эшчәнлек аша махсус күнекмәләргә ия булуына юнәлдерелгән.

5-6 яшьлек баланың психофизиологик үзенчәлекләре аны актив төстә төрле эшчәнлеккә катнаштырып җибәрү мөмкинлеге тудыра. Мәктәпкәчә яшьтәге иң өлкән балалар нинди соң алар? Алардан нәрсә таләп итәргә мөмкин һәм нәрсә таләп итәргә кирәк? Ничек? Аларның яшь үзенчәлекләрен истә тотып, нәрсәләрне гафу итәргә була? Төрле ысул һәм алымнар кулланып, сабыр гына нәрсәләргә ирешергә мөмкин? 5—6 яшь - актив төстә рәсем ясау чоры ул. Ел дәвамында бу балалар 2 меңгә якын рәсем ясый ала. Әлеге чорның казанышлары сурәтләү эшчәнлегенең үсеше белән, кору эшчәнлеге барышында үрнәкне гомуми өйрәнү-күзәтү алымын куллану белән, бердәй формадагы предметларны сурәтләүнең гомумиләштерелгән алымнарын үзләштерү белән характерлана.

Бу яшьтәге баланың аңлап төшенүе, ягъни аңга алуы катлаулы формадагы объектларны анализлавы белән характерлана; фикер йөртүе фикерләү чараларын үзләштерүе (схема рәвешендәге күзаллаулар, тоташ күзаллаулар, үзгәрешләрнең цикллы булуы турындагы күзаллаулар) белән бара; гомумиләштерә белүе, сәбәпле фикер йөртүе, күзаллавы, ирекле игътибары, сөйләме, «мин» образы үсә.

Уку-укыту методик комплексның максаты - баланы шәхес буларак үстерү, аның сәнгать телен һәм милли-мәдәни традицияләрне үзләштерүе аша икетеллелек һәм күп халыклар арасында яшәү шартларына яраклашкан һәм шул шартларга туры килә торган шәхес иреген арттыру.

Уку-укыту методик комплексының бурычлары:

- Балаларны дөньякүләм милли мәдәният җәүһәрләре белән таныштыру.
- Һәрьяктан үскән шәхес тәрбияләү:
  — коммуникатив сыйфатларын үстерү;
  — иҗади эшчәнлек нигезе буларак баланың күзаллау сәләтен үстерү;
  — образлы, ассоциатив хәтерен, игътибарын үстерү;
  — сөйләмен үстерү;
  — стандарт булмаган фикерләвен формалаштыру;
  — координация һәм вак моториканы үстерү.
- Баланың психологик сәламәтлеген саклау һәм ныгыту.
- Сурәтләү күнекмәләрен үстерү.

Уку-укыту методик комплексы укыту материалы эчтәлеген өз-лексез һәм акрынлап катлауландыра бару принцибына корылган.

Программа баланың яшь үзенчәлекләрен искә алып, аның иҗа-ди күнекмәләрен, хезмәт һәм иҗади активлыгын, гомумкульту-ралы үсешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән өч бүлектән тора.

Куелган максат түбәндәге бурычлар белән ачыклана:

- **тәрбияви** – әйләнә - тирә дөньяга иҗат эшчәнлеге аша, шәхси тәҗрибә туплау һәм үз-үзеңне формалаштыруның нигезе буларак кешелекнең рухи тәҗрибәсе аша эмоциональ-кыйммәти мөнәсәбәт формалаштыру;

- **иҗади** - иҗади идеяләрне тормышка ашыруда фактура һәм төсләр уйнавын, стандарт булмаган алымнар кулланып, иҗади сәләтләрне, образлы фикерләүне, фантазия һәм күзаллауны үстерү;

- **техник** - сурәтләү осталыгының (рәсем, сынлы сәнгать һәм композиция) гамәли алымнарын һәм күнекмәләрен үзләштерү.

Сурәтләү һәм кору эшчәнлеге шөгыльләре бала шәхесенең һәрьяклы һәм гармонияле үсешенә, иҗади сәләтләрне ачуга, хезмәт, әхлакый һәм эстетик тәрбия бурычларын хәл итүгә булыша.

Әлеге уку-укыту методик комплексының бу өлкәдә моңарчы булганнарыннан аермалы ягы шунда: ул ике телдә (рус һәм татар телләрендә) төзелгән; милли мәдәният традицияләре белән танышу аша ике телне эзлекле төстә үзләштерүгә, кешелек тудырган иҗат мирасы үрнәкләре белән уен ситуацияләре кулланып, таныштыруга юнәлтелгән. Программа һәр шөгыльнең сурәтләү ысулын җентекле тасвирлап бирүне, аның сурәтләү осталыгы нигезләрен үзләштерүгә юнәлтелгән булуын, балаларны актив танып белүгә һәм иҗат эшенә тартуны күздә тота.

Уку-укыту методик комплексы сурәтләү эшчәнлегенең өч төрен (рәсем ясау, аппликация, әвәләп ясау) һәм кору эшчәнлеген колачлаган бердәм курс булып тора. Санап үтелгән эшчәнлек төр-ләре үзара тыгыз бәйләнгән һәм бөтен уку елы буена бер-берсен тулыландырып барырга тиеш булалар. Программа материалы атнага 2 рәсем ясау, 1 кору шөгыле һәм аларны әвәләп ясау, кору шөгыльләре белән чиратлаштыру аша тормышка ашырыла.

Шөгыльләр М. А. Васильева, В. В. Гербова, Т. С. Комарова редакциясендәге «Программа воспитания и обучения в детском саду» һәм К. В. Закирова, Р. А. Борһанова, Г. А. Галиева редакциясендәге «Программа воспитания и обучения в детском саду (национально-региональный компонент программы)» хезмәтләренә нигезләнеп, күпмәдәниятле тәрбия бирү бурычларын истә тотып төзелде.

Уку елы ахырында балалар түбәндәге күнекмәләргә ия булалар:

- Татарстан, Россия һәм чит ил рәссамнарының сәнгать әсәрләрен, аларның төрләрен (картиналар, китап графикасы, халык кул эшләре), рәсем сәнгатенең төп жанрларын (пейзаж, портрет, натюрморт) аера беләләр;

- сәнгать төрләрендә сурәтләү чараларын (форма, төс, колорит, композиция) таныйлар;

- сурәтләү материаллары үзенчәлекләрен беләләр;

- исәнләшү сүзләрен, кайбер төс һәм төсмерләрне (кызыл, сары, яшел, зәңгәр, кара, ак, алсу һ. б.), күләм төшенчәләрен (зур, кечкенә, зуррак, кечкенәрәк), әйберләрнең пространствода ничек урнашуын (өстә, аста, уртада) таныйлар, аңлыйлар һәм ике телдә (русча һәм татарча) әйтә беләләр;

- дөнья, туган илләре, республикалары, шәһәрләренең (авыл, поселокларының) кайбер истәлекле урыннарын (Кремль, цирк, күперләр, гыйбадәтханәләр, театр һәм музейлар һ. б.) беләләр, милли бәйрәмнәрен тасвирлап бирәләр;

- туган якларының һәм башка төбәкләрнең үсемлекләрен (нарат, өрәңге, каен, миләш һ. б.) һәм хайваннар дөньясын (бүре, төлке, аю һ. б.) таныйлар һәм тасвирлап бирәләр.

**Рәсем ясау:**

- предметларның үзенчәлекле билгеләрен күрсәтеп ясый беләләр (натурадан, күз алдына китереп), сюжетлы композицияләр тудыралар;

- төрле композиция чаралары, сурәтләү материаллары кулланалар;

- халык декоратив-гамәли сәнгате үрнәкләре буенча бизәкләр төшерәләр;

- җылы Һәм салкын, караңгы һәм ачык төсләрне һәм аларның төсмерләрен аералар; гади төсмерләр ясый беләләр (ачыграк һәм сыеграк итеп).

**Әвәләп ясау:**

- үзләштерелгән алымнарны кулланып, натурадан карап һәм күз алдына китереп, үзенчәлекле билгеләрен, төзелешен, пропорциясен күрсәтеп, төрле формадагы предметларны әвәләп ясыйлар;
- савытларны тасмалау, әйләнмәле ябыштырып сылау ысулы белән әвәләп ясыйлар;
- хайван, кош һәм кешенең гәүдә һәм очлыкларына хас хәрәкәтләрне күрсәтеп, аларны конструктив, катнаш ысул белән әвәләп ясыйлар;
- 2—3 фигурадан гыйбарәт катлаулы булмаган эшләнмәләрне аскуймага ныгытып урнаштырып, композиция ясыйлар (сюжетлы әвәләп ясау);
- халык иҗат иткән уенчыкларга таянып, сыннар тудыралар;
- сыгылмалы таякчыклар җыелмасыннан файдалана беләләр.

**Кисеп ябыштыру (аппликация):**

- «Җиде кат үлчә, бер кат кис» мәкале нигезендәге эш алымнарын кулланалар;
- симметрияле итеп кисәләр;
- гармун күрегедәй итеп кисә беләләр;
- ерткалау алымы белән эшли беләләр;
- чит-читләрне каймалап ясыйлар;
- төп геометрик төшенчәләрне (почмак, як, квадрат, өчпочмак һ. б.) беләләр;
- квадрат, түгәрәк, өчпочмаклардан, төсләре буенча аралаштырып, бизәкләр ясыйлар;
- пейзаж композицияләре, тематик ябыштырмалар (аппликацияләр) әзерлиләр.

**Кору эшчәнлеге:**

- корылма үрнәген күзәтеп, аны тасвирлап бирәләр, бу корылманы әзерләү этапларын планлаштыралар, конструктив алымнар табалар;
- рәсемнән карап, корылма төзиләр;
- конус, цилиндр, квадраттан эшләнмәләр әзерлиләр;
- әзер өлге буенча эшлиләр, шартлы билгеләрне аңлыйлар;
- кәгазь белән оригами ысулын (бөкләү, кат-кат бөкләү, киртекләп кисү) кулланып эшлиләр.

| Эшчәнлек төре. Шөгыльнең темасы, № | Программа эчтәлеге | Методик алымнар | Материаллар |
|---|---|---|---|
| | | **Сентябрь. 1 нче атна** | |
| **1. Рәсем ясау: «Тәлинкәдә алмалар».** | • Балаларны алмаларга хас билгеләрнең (төсе, зурлыгы, формасы) сортларына бәйле булуын төшенүгә этәрү.<br>• Гуашь буяулар белән эшләү күнекмәләрен ныгыту.<br>• Нәфасәти (эстетик) кабул итүне үстерү: балалар игътибарын форма һәм төсләр кушылмасы гүзәллегенә юнәлтү. | Россиянең урта полосасында үскән алма сортларын (антоновка, әнис һ. б.) күзәтү. Төсләрен, зурлыкларын, формаларын аерып күрсәтү. Алмаларга хас билгеләрнең сортларына бәйле булуын төшенүгә этәргеч булырлык сораулар бирү. | Ак калын кәгазь түргәге (R10), сары, кызыл һәм яшел төстәге гуашь, пумала, аскуйма, су, салфетка, төрле сорт алмалар, уенчык керпе. |
| **2. Әвәләп ясау: «Урман аланында» (гөмбәләр).** | • Гөмбәләргә хас билгеләрне күрергә һәм ясап күрсәтергә өйрәтү (эшләпә читләренең өскә яки аска таба бөгелеше, батынкы яки кабарынкы булуы, нечкә яки юан төбе һ. б.).<br>• Әвәләп ясау күнекмәсен ныгыту.<br>• Балаларда туган як табигате белән кызыксыну хисе тәрбияләү.<br>• Дөрес итеп ясау алымнарын тәкъдим итү аша тәнкыйтьләп анализлау күнекмәсен үстерү. | Россиянең урта полосасында үсә торган гөмбә рәсемнәрен карау. Әвәләп ясалган үрнәкләрне карау, аларны ясау алымнарына, гөмбәләргә хас билгеләргә (гөмбә эшләпәсе читләренең өскә яки аска таба бөгелеше, батынкы яки кабарынкы булуы, нечкә яки юан төбе һ. б.) игътибар юнәлтү. | Пластилин (балчык), әвәләп ясау өчен такта, салфеткалар, гөмбә рәсемнәре, әзер үрнәкләр, урман аланы макеты, сыгылмалы таякчык. |
| **3. Алдан уйлап, рәсем ясау: «Җәйнең иң гүзәл көне».** | • Образларны аңлап кабул итү, күзаллау сәләтен үстерү. Балаларны җәй көне күргәннәрен искә төшереп, рәсемдә чагылдырырга өйрәтү.<br>• Композиция төзү, кәгазь битен тутырып рәсем ясау, рәсемне кәгазь битенең аскы өлешендә ясау күнекмәләрен үстерү.<br>•Җәйге ял турында сокланып искә алулары аша балаларның иҗади активлыкларын үстерү. | И. Гуринаның «Вышло лето на поля» әсәре эчтәлеген искә төшерү. И. Левитанның «Июнь көне», И. Шишкинның «Имәнлек», картиналары, «Күңелле Сабантуй» китабына Т. Хаҗиәхмәтовның иллюстрацияләрен карау. | Төсле карандашлар яки балавыз бурлар, А5 форматлы ак кәгазь. И. Левитанның «Июнь көне», И.Шишкинның «Имәнлек», «Күңелле Сабантуй» китабына Т.Хаҗиәхмәтов иллюстрацияләре. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **4. Табигый материалдан корып ясау: «Шүрәле».** | • Әзерләнә торган эшләнмә белән чынбарлык дөнья арасында бәй-ләнеш табарга өйрәтүне дәвам итү. • Балалар бакчасы участогыннан, парк яки урманда җыелган агач, куак ботакларын-нан, чыршы һәм нарат күркәләреннән, үсемлек орлыкларыннан пластилин белән беркетеп уенчыклар ясарга өйрәтү аша балаларда туган як табигате белән кызыксыну хисе тәрбияләү. • Эшләнмә өчен материал туплага-нда иҗади күзаллауларны үстерү (Гәүдәсен нәрсәдән ясап булыр? Кечкенә күркә уенчыкның кайсы өлеше өчен кулай булыр? һ. б.). Балаларны татар халкының «Шү-рәле» әкияте белән таныштыру. | Г. Тукайның «Шүрәле» әкиятен уку аша әсәр эчтәлеген искә төшерү; уенчык Шүрәле образын тудыру өчен, әлеге образ турында әңгәмә оештыру; үрнәкне күзәтү, аның гәүдә өлешләрен тоташтыру юлларын аңлату; балалар эшләвен һәм эш нәтиҗәләрен анализлау. | Эшләнмә үрнәге, 2 күркә (зур һәм кечкенә), 4 ботак (аяк һәм куллар), пластилин, пластилин өслекле картон аскуйма; үсемлек орлыклары, җи-ләк-җимеш төшләре (гөмбә эшләпәләре), агач ботаклары. |
| **Сентябрь. 2 нче атна** | | | |
| **5. Рәсем ясау: «Каен һәм имән».** | • Агачларга хас билгеләрне чагыштырырга һәм төрле өлешләрен, пропорцияләрен күрсәтеп сурәтләргә өйрәтү. • Коры өслектә акварель белән эшләү техникасын аңлату. • Туган як үсемлекләре гүзәллеген күрә белергә өйрәтеп, балаларның нәфасәти хисләрен үстерү. | Шөгыль алдыннан балалар бакчасы участогында, парк яки урманда агачларны күзәтү. Балаларда нәфасәти хисләр уяту өчен, рус шагыйре С. Есенинның «Берёза», литвалы М. Вайнилай-тисның «Дуб», татар шагыйре Р. Әхмәтованың шигырьләре белән таныштыру; агачларга хас билге-ләрне, аларның төп өлешләрен, пропорцияләрен чагыштыру өчен, иллюстрацияләрне анализ-лау, өстәмә сораулар бирү. | Акварель буяулар, альбом бите, пумала, аскуйма, су, салфетка; имән һәм каенның төрле ел фасылындагы иллюстрацияләре. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **6. Кисеп ябыштыру: «Гөмбәләр, гөмбәчекләр» .** | • Аскуйманың үзәгенә яки үзәккә якынрак итеп бер оя гөмбәдән композиция төзергә өйрәтү, балалар үзләре күзаллаганча өстәмә детальләр белән бизәү.<br>• Икегә бөкләнгән кәгазь битеннән бердәй ике кисәк кисү алымы белән таныштыру; почмакларны салмак түгәрәкләп кисү алымын ныгыту.<br>• Балаларда урманда үзеңне дөрес тоту һәм сак булу күнекмәләре булдыру. | Гөмбә иллюстрацияләрен карау, үзенчәлекле билгеләрен аерып күрсәтү; яхшы һәм начар гамәл-ләрне дөрес бәяләргә өйрәтү өчен, әңгәмә үткәрү; бердәй ике кисәк кисү алымын аңлату һәм кисеп ябыштыру өчен әзерләнгән предметларны урнаштыру вариантларын күрсәтү. | А4 форматлы сыек яшел төстәге кәгазь бите, бердәй ике ак гөмбә ясау өчен: 3х10 см лы көрән төстәге бер бит кәгазь - шләпәләре, 6х4 см лы сары төстәге турыпочмаклык - төбе; зур ак гөмбә: 8х4 см лы көрән төстәге һәм 5х6 см лы сары төстәге турыпочмаклыклар, кайчы, пумала, җилем, аскуйма, клеёнка, кәгазь кисәкләре өчен тартма, әзерләмәләр салынган тәлинкә, салфеткалар. «Иҗат тартмасы» -алдан ук кисеп әзерләп куелган күбәләкләр, чәчәкләр h. б. яки шул предметларның контурлары сызылган әзерләмәләр. |
| **7. Рәсем ясау: «Татар орнаменты».** | • Татар халкының этник һәм милли-мәдәни үзенчәлекләрен саклау һәм яклау максатыннан, балаларны декоратив-гамәли сәнгатьнең гүзәл төре - татар чигеше белән таныштыру.<br>• Татар орнаменты элементларын кулланып, сурәтне полосада урнаштырырга өйрәтү.<br>• Нәфасәти аңлау-кабул итү, композиция төзү күнекмәләрен үстерү. | Милли чигешләр белән бизәлгән эшләнмәләр карау; халык кул эшләре турында сөйләү. Үрнәкләрне (элементлары, төсләре, композицияләре) анализлау. Манып алу ысулы белән буяу (ромашкалар, яфраклар) алымнарын, пумала очы белән эшләүне (нокталар, дулкынлы сызык) искә төшерү. | Кара төстәге катыргы кәгазь, сары, кызыл һәм яшел төстәге гу-ашь, пумала, аскуйма, су, салфетка, мамык таякчык. |
| **Сентябрь. 3 нче атна** | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **8. Рәсем ясау: «Көнбагышлар».** | • Сары таҗ яфракчыкларының төрле төсмерләрен, орлыклар белән тулы үзәгенең көрән, кара, соры төсләрен рәсемдә күрсәткәндә, балаларда төс тою сәләтен, нәфасәти кабул итүне үстерү.<br>• Көнбагышка хас үзенчәлекле билгеләрне (таҗ яфракчыкларының, сабак яфраклары һәм үзәгенең формалары, төсләре) пумала һәм мамык таякчык белән сылап-сылап ясарга өйрәтү.<br>• Гуашь белән эшләү күнекмәләре булдыру. | Көнбагыш иллюстрацияләрен карау, үзенчәлекле билгеләрен аера белү. Пумала белән сылап-ышкып (таҗ яфракчыклары), мамык таякчык белән (көрән, кара, соры төстәге орлык тулы үзәк) ясау алымнарын аңлату, күрсәтеп искә төшерү, композиция төзү күнекмәләрен үстерү өчен, предметларны төрлечә урнаштырып карау. | А4 форматлы зәңгәрсу төстәге кәгазь бите, сары һәм яшел төсләрнең төрле төсмерләрендәге гуашь, пумала, аскуйма, су, салфетка, мамык таякчык. Чын көнбагыш яки иллюстрация. |
| **9. Әвәләп ясау: «Көз» фоторамасы.** | • Көзге күренешләрен искә төшерүче әйберләрдән (яфраклар, яшелчәләр, җиләк-җимешләр, гөмбәләр) төрле форма һәм пропорцияләрне күрсәтеп, рельефлы рама ясарга өйрәтү.<br>• Әвәләп ясауның инде таныш алымнарын кулланып, предметларга хас билгеләрне күрсәтә алу күнекмәсен ныгыту.<br>• Дизайнерлык күнекмәләре формалаштыру. | Фоторәсем рамы үрнәкләрен карау-өйрәнү, аны әвәләп ясау алым-нары турында сөйләшү. Нәфис сүз аша шөгыль темасы белән кызыксынуларны көчәйтү. | Тыгыз картоннан ясалган 10x15 см лы әзер фоторама, әвәләп ясау өчен такталар, салфетка, сыгылмалы таякчык, яфраклар, яшелчәләр, җиләк-җимешләр, гөмбә иллюстрацияләре, үрнәкләре. |
| **10. Рәсем ясау: «Түбәтәй».** | • Декоратив-гамәли сәнгать предметлары белән таныштыруны дәвам итү. Бизәк элементларын сайлап, ал арны дөрес урнаштырып, татар ир-егетләренең милли баш киемен бизәргә, түгәрәк эченә рәсем төшерергә өйрәтү.<br>• Татар милли орнаментын таный һәм элементларын атый белүгә ирешү.<br>• Түбәтәй бизәүгә иҗади омтылыш уяту. | Татар ир-егетләренең баш киемнәрен карау. Татар халкының декоратив-гамә-ли сәнгате турында әңгәмә үткәрү, татар милли орна-менты элементларын өле-шчә генә рәсемгә төшереп күрсәтү, аларны урнашты-ру вариантлары турында фикер алышу, индивиду-аль эш, контроль, бәяләү. Татар халык уены «Түбәтәй». | Гуашь, түбәтәй үрнәге, уртача һәм нечкә пумала, салфеткалар, сулы банка, татар халык орнаменты, түбәтәй рәсемнәре. |
| **11. Киригами техникасы белән кәгазьдә кору: «Кыргый хайваннар».** | • Турыпочмаклы кәгазь битен урталай бөкләп, детальләр өстәп, күләмле фигуралар ясарга өйрәтү.<br>• Чынбарлыкта күргәннәрен | Иллюстрацияләр карап, кыргый җәнлекләрнең тышкы кыяфәтләре, үзенчәлекләре турында күзаллау формалаштыру; | Кыргый җәнлекләр ил люстрацияләре, А5 фор матлы йомшак картон, кайчы, җилем, пумала, аскуйма, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | үзләре ясаячак уенчыкларда гәүдәләндерергә өйрәтүне дәвам итү.<br>• Эш өчен кирәкле материалны мөстәкыйль сайлый белү күнекмәсен ныгыту. | үрнәкне күзәткәндә һәм өлешчә аңлатып күрсәткәндә кору күнекмәләрен үстерү; балалар корган эшләнмәнең дөрес булуын уен алымы белән бәяләүгә ирешү һәм җәнлекләргә карата кайгыртучан мөнәсәбәтләрен хуплау. | клеенка, киселгән кисәкләр өчен тартмачык, әзерләмәләр куелган савыт, сафеткалар. «Иҗат тартмасы» кечкенә төсле кәгазь кисәкләре. |
| **Сентябрь. 4 нче атна** | | | |
| **12. Рәсем ясау: «Яшелчәләр уңышы».** | • Акварельнең сурәтләү мөмкинлекләре белән (үтә күренмәле, бер төс өстенә икенчесен сылаганда, төсе үзгәрә) таныштыру.<br>• Акварель белән эшләү ысулларын (рәсем ясар алдыннан, пумаланы суга манып, һәр буяуга берәр тамчы су тамызып, буяуларны җебетергә; бер төстәге буяуның төрле төсмерләрен алу өчен, аны су белән сыекларга өйрәтү.<br>• Төп үрнәк формадан аермаларны күрә белүләрен үстерү.<br>• Табышмак җавапларын табуларына ирешү. | Яшелчәләр турында шигъри табышмаклар куллану, төрле яшелчәләргә (кыяр, помидор, суган һ. б.) хас төп формаларны күзәтү-өйрәтү, акварель белән эшләү алымнарын күрсәтү, рәсем турында тулы итеп сөйләргә этәрерлек сораулар бирү. | Акварель буяулар, альбом бите, пумала, аскуйма, су. Акварель буяулар белән ясалган яшелчә рәсемнәре һәм яшелчәләр. |
| **13. Кисеп ябыштыру: «Вазада көзге яфраклар бәйләме».** | • Балаларны симметрияле формалар кисүнең яңа ысулы белән таныштыру.<br>• Эшләү барышында төрле материалларны яраштыру (кәгазь һәм табигый материалларны) күнекмәсен ныгыту.<br>• Көзге төсләр гүзәллеген күреп соклану хисен тәрбияләү.<br>• Балаларны Е. Трутневаның «Листопад» шигыре белән таныштыру. | Төрле иллюстрацияләр кулланып, көзге төсләр турында әңгәмә үткәрү, Г. Тукайның «Көз» шигыре аша туган як табигате белән кызыксыну уяту, бергәләп көзге яфракларны карау, аларны бәйләм итеп, вазага куярга өйрәтү; симметрияле итеп кисү ысулларын күрсәтү. Аңлату, эшкә дәртләндерү, тырышлыкларын хуплау. | А4 форматлы төсле йомшак картон, кайчы, җилем, пумала, аскуйма, клеёнка, кисемнәр өчен тартма, әзерләмәләр салынган савыт, киптерелгән яфраклар, яфрак шаблоннары, карандаш, салфеткалар. «Иҗат тартмасы» - кечкенә төсле кәгазь кисәкләре, көзге яфраклар рәсемнәре. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **14. Рәсем-миниатюра: «Алтын көз».** | • Миниатюра жанры белән таныштыру.<br>• Дымлы кәгазь битендә акварель буяулар белән рәсем аша көз төсмерләрен чагылдырырга өйрәтү.<br>• Балаларның сүзлек запасын сыйфат сүз төркеме тасвирлары белән (ачык кызыл, алтын, ялкындай кызыл, алсу, чиядәй кызыл һ. б.) баету. | И. И. Шишкинның «Көзге пейзаж», И. И. Левитанның «Алтын көз» картиналары репродукцияләре аша балаларның күңелләрен кузгату. Табышмаклар кулланып, көз турында сөйләшү. Рәсем фонын әзерләгәндә, дымлы кәгазь битендә акварель буяулар белән эшләү техникасын җентекләп аңлату һәм эшләп күрсәтү. Мөстәкыйль эшләгәндә, башкарылган эшләрне анализлаганда, балаларда шатлык һәм канәгатьлек хисе уяту. | Акварель өчен А6 форматлы кәгазь бите, уртача һәм нечкә пумала, аскуйма, су, салфетка, балавыз бурлар, җилем, рамка өчен А5 форматлы тыгыз кызыл картон. |
| **Октябрь. 1 иче атна** | | | |
| **15. Рәсем ясау: «Көзге келәм» (яфракларны басып рәсем төшерү).** | • Традицион булмаган сурәтләү материалларын (көзге яфраклар) кулланырга өйрәтү.<br>• Көз төсмерләрен (ачык кызыл, алтын, ялкындай кызыл, алсу, чиядәй кызыл һ. б.) рәсем аша җиткерү күнекмәләрен ныгыту.<br>• Табигать күренешләренә игътибар итү, күзәтү, алардагы үзгәрешләрне күрү сәләтен үстерү. | «Кайсы агач яфрагы» дидактик уены аша балалар игътибарын шөгыль темасына юнәлтү, табигать предметлары белән сурәтләү мөмкинлекләрен күрсәтү. | Төрле агачларның көзге яфраклары, гуашь, уртача пумала, аскуйма, су, салфетка, А4 форматлы зәңгәр тыгыз кәгазь. |
| **16. Әвәләп ясау: «Тыл-сымлы кошлар».** | • Әвәләп ясаганда, кош образын күз алдына китереп, аны тәэсирле итеп чагылдыра белү сәләтен формалаштыру.<br>• Балаларның балчыкны (пластилинны) ике уч белән түгәрәкләп яки туры итеп тәгәрәтү, сузу, җәю, чеметкәләп кую күнекмәләрен ныгыту,әвәләп ясалган сынның кытыршы урыннарын тигезләргә өйрәтү.<br>• Төрле эш төрләрен (әвәләп һәм табигый материаллар кулланып ясау) берләштереп барырга өйрәтүне дәвам итү. | Иллюстрацияләр карап, әдәби әсәрләрдән өзекләр укып, тылсымлы кош образын тирә-юньдәге кошлар белән чагыштырып анализлау. Эш башкару ысулларын һәм алымнарын аңлата барып, үрнәкләргә анализ ясау. | Балчык (пластилин), әвәләп ясау өчен такталар, салфеткалар, кош уенчыгы, сыгылмалы таякчык, үсемлекләрнең канатлы орлыклары, рәссам И. Я. Билибинның «Иван-царевич һәм Соры бүре» һәм рәссам Н.Кочергинның «Канатлы ат» картиналарының китап иллюстрацияләре. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **17. Рәсем ясау: «Сыбызгы үрдәк».** | • Балаларның нәфасәти кабул итү сәләтләрен үстерү. Халык уенчыклары белән кызыксыну уяту.<br>• Гомумиләштерелгән кош образын рәсемдә сурәтләү осталыгын камилләштерү.<br>• Сыбызгы үрдәк уенчыгын күрсәтеп, балаларның иҗатка омтылышын үстерү. | Халык уенчыгы - сыбызгы үрдәкне карау, уенчыкны чын кош белән чагыштырып, гәүдә өлешләренең туры килү-килмә-вен анализлау (башлары, гәүдә һәм койрыклары бар, уенчыкта тәпиләр урынына аскуйма, кау-рыйлары урынына бизәк), сары буяуны тап-тап итеп төшереп, сыбызгы үрдәк рәсемен аңлатып-күрсәтеп ясау, күкрәгендәге, башы һәм ян-якларындагы бизәк элементларын һәм аларның урнашуын җентекләп күзәтү. | Гуашь, салфеткалар, сулы банка, нечкә пумала, А4 форматлы тыгыз кәгазь, сыбызгы үрдәк уенчыклары һәм рәсемнәре. |
| **18. Кору: «Зоопарк».** | • Зур булмаган берничә яссылыкны берләштерергә өйрәтү.<br>• Корылманы, кирәкле төзү материаллары сайлап, тагы да зурайту күнекмәсен ныгыту.<br>• Кору, күз белән чамалау сәләтен, пөхтәлекне, ассоциатив фикерләүне үстерү. | Балаларга зоопарк территориясенең төрле хайваннар вольерларын берләштерүен, вольер рәшәткәләренең нык булырга тиешлеген төшендерү. Төзелешне терәк баганалар урнаштырудан, аларны рәшәткәләр белән тоташтырудан башларга кирәклеген аңлатып эшләп күрсәтү. Балаларны зоопарк территориясен төзекләндерү һәм уңайлы итү эшләренә җәлеп итү. | Һәр бала өчен төзү материалы, киригами техникасы белән әзерләнгән уенчык кыргый җәнлекләр, А3 форматлы кәгазь бите, фломастерлар, агач сыннары. |
| **Октябрь. 2 нче атна** | | | |
| **19. Рәсем ясау: «Алтын хохлома».** | • Россия халыкларының мәдәни үзенчәлекләрен саклау максатыннан, балаларны декоратив-гамәли сәнгатьнең үсемлек-чәчәк бизәкләре мотивы белән охшаш яңа төре-хохлома бизәкләре белән таныштыру.<br>• Сылап-сылап рәсем төшерү (ромашкалар, яфраклар), пумала очы белән эшләү (нокталар, дулкын-лы сызык) алымы кулланып, балаларны полосада бизәк төшерергә өйрәтү.<br>• Нәфасәти кабул итүне, композиция тоемлауны үстерү. | Хохлома бизәк төшерелгән эшләнмәләрне алдан ук бергәләп карап кую. Хохлома һөнәре турында сөйләү. Үрнәкләрне (элементлар, төс, композиция) анализлау. Сылап-сылап рәсем төшерү (ромашка, яфраклар), пумала очы белән ясау (нокталар, дулкынлы сызык) алымнарын гамәли күрсәтү. | 29х10 см лы кара төстәге кәгазь тасма, сары һәм яшел төстәге гуашь, пумала, аскуйма, сулы банка, салфетка, мамык таякчык. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **20. Кисеп ябыштыру: «Песнәкләр».** | • Сурәтне өлешләрдән төзергә, агач ботакларын, яфраклар ясап, эшләнмәне тулыландырырга өйрәтүне дәвам итү.<br>• Ассоциатив фикерләүне үстерү, кош гәүдәсе өчен кисеп ясалган өлешләрне дөрес урнаштыру күнекмәсен камилләштерү.<br>• Материаллар белән пөхтә һәм сак эшләргә өйрәтү. | Очып баручы кошларны һәм аларның рәсемнәрен күзәтү, койрык ясау өчен симметрияле итеп кисүне аңлатып эшләп күрсәтү, очып баручы кошның канатлары җәелешен, җим чүпләүче яки чыркылдаучы песнәкнең гәүдә өлешләрен ничек кисеп ясауны сөйләшеп хәл итү. | А5 форматлы зәңгәр төстәге кәгазь бите, 6х4 см лы сары турыпочмаклык (гәүдәсе өчен), 6х3 см лы кара турыпочмаклык (койрыгы өчен), 3х3 см лы кара турыпочмаклык (башы өчен), 6х3 см лы зәңгәр турыпочмаклык (канатлары өчен), фломастерлар яки карандашлар, җилем, җилем пумалалары, клеёнка (һәр балага), салфеткалар, пычаклар. |
| **21. Рәсем ясау: Е. Чарушинның «Бәбкәләре белән Үрдәк» әсере буенча.** | • Кошларны төсле таплар ярдәмендә ясарга, аларның үзенчәлекләрен, характерлы торышларын позаларын рәсем аша җиткерергә өйрәтүне дәвам итү.<br>• Сурәтне кәгазь битен тутырып ясауга, акварель буяуларны алдан бераз юешләп эшләү күнекмәләрен ныгыту.<br>• Әдәби әсәрләрдән тәэсирләнүләренә ирешү. | Рус язучысы һәм графигы Е. Чарушин әсәрен искә төшереп, әлеге әсәргә, иллюстрацияләр карап, балаларда шөгыль темасына карата кызыксыну уяту, кошлар гәүдәсе төзелеше, очканда, хәрәкәт иткән дәге торышлары турында күзаллау булдыру. Шул арны балалар әйтеп торганда күрсәтү. | Акварель буяулар белән ясау өчен А4 форматлы кәгазь бите, уртача һәм нечкә пумала, аскуйма, су, салфетка. |
| **Октябрь. 3 нче атна** | | | |
| **22. Рәсем ясау: Е. Чарушинның «Тюпа, Томка һәм саескан» әсәре буенча.** | • Күмернең сурәтләү мөмкинлекләре һәм аның белән эшләү тәртибен аңлату.<br>• Хайваннарга хас үзенчәлекләрне һәм аларның торышларын рәсем аша җиткерә белергә өйрәтүне дәвам итү.<br>• Әдәби әсәрләргә яңа сурәтләү материалы - күмер белән иллюстрация ясаганда, балаларның образлы күзаллауларын үстерү. | Балаларны Е.Чарушинның «Тюпа, Томка һәм саескан» әсәренә үзе ясаган график сурәтләрне аңлауга этәрү, хайваннар гәүдәсе, башы, тәпиләре халәтен карау-өйрәнү, күмер белән эшләү эзлеклелеген (контурны ясап чыгу, штрихлау, күләгәләү) күрсәтү. | А4 форматлы кәгазь бите, сурәтләү күмере яки лейкопластырь белән уралган, тотарга уңай формалы гадәти күмер, дымлы салфетка. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **23. Әвәләп ясау: «Дымково колыны».** | • Балаларны рус халык иҗат үрнәге -Дымково уенчыгы белән таныштыруны дәвам итү. Халык һөнәрчеләре хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.<br>• Балаларны халык иҗаты үрнәкләре (Дымково мотивлары) буенча сыннар әвәләп ясарга өйрәткәндә, эшләүнең катнаш ысулын куллану.<br>• Уенчыкка хас үзенчәлекләрне күрсәтү өчен, әвәләп ясауның мөһим ысулларын (тартып сузу, чеметеп кую, сылау, тигезләү) кулланударына ирешү. | Шигырь уку, Дымково уенчыкларын һәм аларның рәсемнәрен карап, охшашлыкларын һәм аермаларын таптыру. Бөтен бер балчык йомарламыннан колынның гәүдәсен һәм аякларын әвәләп ясап күрсәтү, муенын, башын, ялын, койрыгын ничек ясауны ачыклау өчен, сораулар бирү. | Балчык, әвәләп ясау такталары, салфеткалар, сулы банка, Дымково уенчыклары. |
| **24. Рәсем ясау: «Дымково колынын бизәү».** | • Яңа кызыклы юллар табып, Дымково бизәкләре элементларын бергә кушарга өйрәтү.<br>• Балаларның Дымково уенчыклары, би-зәкләре, Дымково уенчык хайваннарын бизәү эзлеклелеге турындагы белемнәрен ныгыту.<br>• Россия халыкларының декоратив сәнгате белән кызыксынуларын арттыру. | Балаларның алдан ниятләп эшләүләренә ирешү өчен, уен ситуациясе тудыру, рәсемнәр, таблицалар һәм Дымково уенчыкларын карау. Нәфис сүз, балаларны хуплау, эшчәнлекләрен бәяләү. | Гуашь, ак буяу йөгертелгән Дымково сыннары, сулы банка, салфеткалар, рәсемнәр-таблицалар, әзер Дымково уенчыклары. |
| **25. Кәгазьдән кору: «Төремкәй».** | Балаларны җәнлек фигураларын кәгазьдән бөкләп ясарга өйрәтү, бөкләү этапларын билгеләү, җәнлек сыннарын бердәм сюжетка берләштерү.<br>• Таныш булган җәнлек сыннарының башка вариантларын ясауга этәрү.<br>• Халык авыз иҗаты белән кызыксынуны үстерү. | Нәфис сүз, уен алымы, әкият өчен ясалган рәсемнәр аша алдан уйлап эшләүгә этәрү; кәгазьне бөкләү этапларын аңлатып эшләп күрсәтү. Индивидуаль эш, контроль, бәяләү. | "Теремкәй" әкияте иллюстрацияләре, ак, көрән, яшел, соры, әфлисун төсләрендәге шакмаклар, җилем, пумала, аскуйма, салфетка, А4 форматлы фон, балавыз бурлар. |
| **Октябрь. 4 нче атна** | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **26. Рәсем ясау: «Өй күренә тәрәзәдән».** | • Төркем балалары яшәгән урам атамалары белән таныштыру аша балаларда туган җиргә мәхәббәт тәрбияләү. • Берничә подъезддан, күп санлы тәрәзәләрдән гыйбарәт шәһәр йортларын рәсем аша тасвирларга өйрәнү. • Балаларны, иҗади рәвештә якын килеп, рәсемне тулыландырырга этәрү, күзәтүчәнлекләрен, игътибарларын арттыру. | Иң якын балалар бакчасына, йортка экскурсия үткәреп, шөгыль темасына кызыксыну уяту. Йорт төзү эшенең нәрсәдән башлануын, экскурсиядә күргән йортның өлешләрен, үзенчәлекләрен балалар белән искә төшерү. Аңлатып күрсәтә бару. | Гуашь, А4 форматлы кәгазь бите, пумала, салфеткалар, сулы банка. |
| **27. Кисеп ябыштыру: «Трамвайда куяннар».** | • Шәһәр транспортына хас үзенчәлекләрне җиткерә белергә өйрәтү. • Квадрат һәм турыпочмаклык почмакларын түгәрәкләп кисү, тар кәгазь тасмалар кисеп алу күнекмәләрен ныгыту. Балаларның пассажирларны ясаганда иҗади мөстәкыйльлекләренә ирешү. | К. И. Чуковскийның «Тараканище» әсәренә иллюстрацияләрне карау. Форма үзенчәлекләрен, өлешләрен билгеләү, кисеп алу ысулларын, ябыштыру эзлеклелеген искә төшерү. | К. И. Чуковскийның «Тараканище» әсәренә иллюстрацияләр, А4 форматлы ачык төстәге кәгазь, 19х5 см лы сары һәм кызыл, 3,5х14 см лы зәңгәрсу төстәге турыпочмаклыклар, җилем пумаласы, клеенкалар, салфеткалар, төсле карандашлар. |
| **28. Рәсем ясау: «Автобус».** | • Транспортның төп өлешләре, детальләре формасын, пропорцияләрен, урнашу тәртибен рәсем аша җиткерергә өйрәтү. • Карандашны төрлечә басып, рәсемне пөхтә итеп буяу осталыгын үстерү. • Балаларны яңа автобус маршрутлары, туган шәһәрнең истәлекле урыннары белән таныштыру, ул урыннарны бәяләүләренә ирешү. | Балалар бакчасына якын узган юл буена чыгып, транспорт төрләрен күзәтү. Бакчага кайткач, автобус өлешләрен искә төшерү. Күрсәтеп аңлата бару. | Төсле карандашлар, балавыз бурлар, А5 форматлы ак төстәге кәгазь бите, автобус рәсемнәре. |
| **Ноябрь. 1 нче атна** | | | |
| **29. Рәсем ясау: «Безнең шәһәр урамы».** | • Балаларда туган шәһәрләренә мәхәббәт тәрбияләү, үзләре | Әйләнә-тирә белән таныштыру аша әхлакый күзаллаулар | Төсле карандашлар яки балавыз бурлар, А5 форматлы ак |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | яшәгән урам атамалары белән таныштыруны, шул урамнардагы биналарны (балалар бакчасы, мәктәп, кибет һ. б.) искә төшереп әйтүне дәвам итү. • Балаларны вазифаларына бәйле булган корылма үзенчәлекләрен рәсем аша күрсәтергә өйрәтүне дәвам итү. • Сурәтне тулыландыру күнекмәсен ныгыту. | формалаштыру, шөгыль алдыннан экскурсия оештырып, шул турыда сөйләшү, рәсем ясагандагы эзлеклелекне искә төшерү. Индивидуаль ярдәм, тырышлыкларын хуплау, мактау. | кәгазь бите, якындагы урам биналары фотосу-рәтләре. |
| **30. Әвәләп ясау: «Урман аланында».** | • Гәүдә өслеге фактурасын сыгылмалы таякчык кулланып җиткерү аша җәнлекләрне катнаш ысул белән әвәләп ясауга өйрәтүне дәвам итү. • Гадәти хәрәкәтләрне күрсәтә торган әвәләп ясау күнекмәләрен шомартуны дәвам итү. • Сюжетлы уен әзерләү ниятләрен үстерү. | Педагогик ситуация (уен, сораулар, нәфис сүз, әңгәмә) тудырып, әхлакый күзалау формалаштыру, аңлатып күрсәтә бару. Индивидуаль ярдәм, тырышлыкларын хуплау. | «Урман аланы», пластилин, әвәләп ясау такталары, уенчык җәнлекләр, салфеткалар. |
| **31. Рәсем ясау: «Сабый портреты».** | • Төсле таплардан кеше гәүдәсен ясарга, аның төзелешен, пропорцияләрен рәсем аша җиткерергә өйрәтү; тән төсен күрсәтү өчен, буяуларны кушу. • Акварель буяулар белән ясау, палитрадан файдалану күнекмәләрен ныгыту. • Сурәтләнә торган предмет һәм әзер эшләрне чагыштырып, балаларның үзләре һәм башка балалар ясаган рәсемнәргә бәя бирү күнекмәләрен үстерү. | Сурәтләү эзлеклелеген күрсәтүгә этәрүче сораулар бирү, курчакны карау, әңгәмә үткәрү. Индивидуаль ярдәм, балалар хезмәтен хуплау, контроль, эшчәнлеккә бәя бирү. | А4 форматлы кәгазь акварель буяулар, ур-тача һәм нечкә пумала, аскуйма, су, салфетка, курчак. |
| **32. Кору: «Йөк машиналары».** | • Кору ысулларын искә төшерү һәм ныгыту, үрнәкне анализлау, билгеле бер | Россия һәм Татарстанда чыгарылучы йөк машиналары (КамАЗ, МАЗ, ГАЗ, КрАЗ) белән | Һәр балага кору материалы, уенчык йөк машиналары һәм рәсемнәре. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | (эзлеклелектә төзү күнекмәсен камилләштерү.<br>• Кубикларны борыслар белән, пластиналарны кирпечләр белән алмаштырырга өйрәтү.<br>• Россия һәм Татарстан территориясендә эшләп чыгарыла торган йөк машиналары (КамАЗ, МАЗ, ГАЗ, КрАЗ) белән таныштырып, горурлык хисләре тәрбияләү. | таныштыру аша әхлакый күзаллаулар формалаштыру.<br>Шөгыльгә кадәр якындагы юл буена чыгу, күзаллаулар булдыру өчен әңгәмә оештыру. Кору өчен кирәкле материалларны ачыклау, йөк машиналарын кору эзлеклелеген искә төшерү. Индивидуаль ярдәм, тырышлыкларын хуплау. | |
| **Ноябрь. 2 нче атна** | | | |
| **33. Рәсем ясау: «Йөк машинасы».** | • Йөк автомобиленең төп өлешләре формаларын, детальләрен, пропорцияләрен, ничек урнашуларын рәсем аша җиткерә белергә өйрәтү.<br>• Балаларның, сурәтне үзләре уйлаганча тулыландырып, машина төзү өчен кирәкле материаллар турында күзаллауларын киңәйтү.<br>• Балалардан шәһәрнең (авылның, районның) зур төзелешләренә йөк транспорты маршрутлары сыздырып, туган яклары тормышына үзләренең катнашлары булу хисе тәрбияләү. | Йөк автомобиленең төп өлешләрен, детальләрен, пропорцияләрен һәм ничек урнашуларын искә төшерү. Балалар әйтеп торган эзлеклелектә аларны күрсәтә бару. Шәһәрнең (авылның, районның) зур төзелешләренә йөк транспорты маршруты сыздырып һәм шул турыда әңгәмә оештырып, эшкә уен рәвешендә анализ ясау. | Гуашь, А4 форматлы кәгазь бите, пумала, салфеткалар, сулы банка, йөк автомобильләре рәсемнәре. |
| **34. Кисеп ябыштыру: «Лалә чәчәкләре чигелгән алъяпкыч».** | • Алъяпкыч силуэты өстендә татар орнаменты элементларыннан гыйбарәт сурәт урнаштырырга өйрәтү.<br>• Симметрияле формаларны кисү күнекмәсен ныгыту. Татарстан халыкларының этник һәм милли-мәдәни үзенчәлекләрен саклау һәм яклау максатыннан | Иң элек татар чигешләре белән бизәлгән кульъяулыклар, сөлгеләр, яулыклар, мендәр тышлары һәм япмалары, тәрәзә каша галарын һ. б. күрсәтү. Татар халкының кул эшләре турында искә төшереп сөйләшеп алу. Үрнәкләрне (элементлар, төсләр, Композицияләр) анализлау. Симметрияле формаларны кисү һәм бизәктә элементларны | Алъяпкыч силуэты, кайчы, җилем, пумала, аскуйма, клеёнка, кисүдән калган чүп-чар өчен тартма, әзерләмәләр өчен савыт, салфеткалар. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | балаларны татар чигеше белән таныштырганда, композиция хисе һәм, нәфасәти кабул итүне үстерү. | чиратлаштыру ысулларын искә төшерү. | |
| **35. Рәсем ясау: «Купшы күлмәк».** | • Балаларны сарафан формасын рәсемдә күрсәтергә өйрәтү.<br>• Сарафан итәгенә, изүләренә рус милли бизәге төшереп, балаларның иҗади сәләтләрен үстерү.<br>• Балаларны дежур торучы вазифаларын (шөгыль өчен тәрбияче әзерләгән материалларны таратып чыгу, ахырдан җыеп алу һ. б.) мөстәкыйль төстә һәм җиренә җиткереп башкарырга күнектерү. | Биремне уен мизгеле кулланып аңлату. Сарафан рәсемен ничек ясарга кирәклеген һәм ясау тәртибен аңлату һәм күрсәтеп эшләү. Балаларга, алдан күзаллап эшләүләренә ирешү өчен, сораулар бирү. | Төсле карандашлар, балавыз акбурлар, А5 форматлы кәгазь бите, төрле фасондагы курчак сарафаны рәсемнәре. |
| **Ноябрь. 3 нче атна** | | | |
| **36. Рәсем ясау: «Әкияти йорт».** | • Әкияти образга хас үзенчәлекләр белән тулыландырып, бина төзелешен рәсем аша күрсәтә белергә өйрәтү.<br>• Алдан ниятләп куелган эшне ахырына җиткерү зарурлыгын төшендерү.<br>• Әзер образга нәфасәти мөнәсәбәт, аны нәфасәти бәяли белү күнекмәләре булдыру. | Әкияти образлар һәм алар яшәгән йортлар турында әңгәмә үткәрү. Йортны төзү эзлеклелеген, аның төп өлешләрен, төзү материаллары үзенчәлекләрен (төс, фактура) рәсемдә чагылдыруны искә төшерү. | Акварель буяулар өчен А4 форматлы кәгазь бите, уртача һәм нечкә пумала, аскуйма, су, салфетка, әкиятләргә ясалган иллюстрация-ләр. |
| **37. Әвәләп ясау: «Сертотмас үрдәк».** | • Җәнлекләрне, кошларны катнаш ысул белән әвәләп ясарга өйрәтүне дәвам итү.<br>• Композиция төзү осталыгын үстерү, предметларның зурлыкларын чамалап ясарга, аскуймага урнаштырырга, хәрәкәтләрен, позаларын эшләнмәдә күрсәтә белергә өйрәтү.<br>• Язучы А. Алишның «Сертотмас үрдәк» | А.Алишның «Сертотмас үрдәк» әкиятен уку һәм аны анализлау аша балаларда тапшырылган эшне башкарып чыгу җаваплылыгы тәрбияләү, шул рәвештә балаларны шөгыль темасына этәрү. Әкияткә ясалган иллюстрацияләрне карап, андагы җәнлек фигураларын ничек әвәләп ясарга кирәклеген хәл итү. Персонажларның | Пластилин җыелмасы, 10 см диаметрлы аскуйма, әвәләп ясау өчен такталар, салфет-калар, сыгылмалы таякчыклар, картон-нан киселгән агач фигуралары. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | әкияте белән таныштырганда, балаларда тапшырылган эшне башкарып чыгу җаваплылыгы тәрбияләү. | хәрәкәтләрен һәм позаларын күрсәтеп, аларны аскуймага урнаштыру ысулларын күрсәтү. | |
| **38. Рәсем-коллаж ясау: «Көз белән хушлашу».** | • Балаларның ел фасыллары (көз) турындагы күзаллауларын баету максатында, рәсем эчтәлеген алдан уйлап куярга өйрәтү.<br>• Балаларның, шөгыльләр барышында һәм көндәлек тормышта алган белемнәре-нә таянып, иҗатка омтылышларын арттыру.<br>• Балалар игътибарын туган якның матурлыгына һәм ел фасыллары алмашынуына юнәлтеп, күзәтүчәнлекләрен һәм нәфасәти кабул итүләрен үстерү. | Башка балаларның көз темасына элек әзерләгән эшләрен карап, аларны үз эшләренең эчтәлеген, сюжетын уйларга этәрү. Коллаж-рәсемне төзү алымнарын күрсәтү. Балаларның әзер эшләрен карап, анализ ясап, туган як табигатенең гүзәллеген һәм үзенчәлекләрен күрсәтү. | А4 форматлы кәгазь би-те, карандашлар, фломастерлар яки балавыз акбурлар, киптерелгән үсемлекләр, җилем, җилем өчен пумала, салфетка, балаларның көз темасына эшләре, Татарстан районнары авыл хуҗалыгында көзге эшләрнең фотосурәтләре яки иллю-страцияләре. |
| **39. Табигый материалдан кору: «Гаҗәп кешеләр».** | • Балаларны иҗади образлар тудыруда кулланылачак табигый материал үзенчәлекләрен (форма, фактура) күрә, тоя белергә өйрәтү.<br>• Үрнәкләрне, иллюстрацияләрне анализлау осталыкларын үстерү; эш өчен кирәкле материалны мөстәкыйль рәвештә сайлый белүләренә ирешү.<br>• Ассоциатив фикерләүне үстерү. | Үрнәкне карау, күзәтү, эшне аңлатып, күрсәтә бару. Индивидуаль эш, контроль, бәяләү. | Һәр бала өчен имән чикләвеге һәм агач ботагы, пластилин, 10 см диаметрлы нык аскуйма, шундый эш-ләнмә үрнәкләре һәм рәсемнәре. |
| **Ноябрь. 4 нче атна** | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **40. Рәсем ясау: «Виноград тәлгәше» (бөке белән баскалау).** | • Эш барышында төрле материаллар һәм эш кораллары кулланып карау теләге уятып, балаларны яңа иҗади эзләнүләргә этәрү.<br>• Образның тәэсир итү көчен рәсем аша биргәндә, төрле төс төсмерләрен файдалану осталыгын ныгыту.<br>• Иҗади күз алдына китерүне үстерү.<br>• Молдаван шагыйре Г. Виеруның «Виноградная лоза» шигыре белән таныштыру, төрле милләт (бу очракта молдаван) вәкилләре, аларның гореф-гадәтләре, фольклоры турында күзаллау тудыру. Өлкәннәр хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү. | Шагыйрь Г. Виеру шигырен уку һәм анализлау аша балаларда төрле милләт вәкилләре, гореф-гадәтләре, фольклоры турында күзаллау тудыру. Өлкәннәр хезмәтенә, төрле халыкларның мәдәниятенә, традицияләре һәм гореф-гадәтләренә хөрмәт хисе тәрбияләү. Иллюстрацияләр карап, виноград тәлгәше сурәтен ясау ысулларын билгеләү. Күләмле сурәт килеп чыксын өчен, төс төсмерләрен куллану һәм бөке белән баскалау ысулларын күрсәтү. | А4 форматлы кәгазь бите, аксыл шәмәхә, шәмәхә, ачык һәм куе яшел төстәге гуашь, салфеткалар, су. Виноград тәлгәше иллюстрациясен ясау өчен бөке куелган тәлинкә. |
| **41. Кисеп ябыштыру: «Кызык клоуннар».** | • Клоунның тән әгъзалары торышын үзгәртеп, хәрәкәтне күрсәтә белергә өйрәтү.<br>• Симметрияле һәм парлап кисүдә композицион күнекмәләрне һәм алымнарны ныгыту.<br>• Клоун фигурасын төрле атрибутлар белән тулыландыруда, чәч рәвешен сайлауда иҗади якын килүгә ирешү. | Курчак клоуннарны, рәсемнәр карау, аңлату, әңгәмә үткәрү, эш алымнарын күрсәтү, тәртибен аңлату. | Хәрәкәтне күрсәтү өчен киселгән детальләр, А4 форматлы ачык тондагы кәгазь бите, клоун йөзен ясау өчен 5х5 см лы квадрат, гәүдәсе өчен 10х6 см лы турыпочмаклык, 7х8 см лы ике төрле ачык төстәге 2 буй кәгазь, «ижат тартмасы» һәм аңа салынган ачык, фактуралы, шома кәгазь кисентеләре (ботинкалары, паригы, кием бизәкләү өчен), җилем, җилем пумаласы, һәр бала өчен клеёнка. |
| **42. Рәсем ясау: «Дуслык әйлән-бәйләне».** | • Милли киемдәге кеше фигурасын, аның гади кул хәрәкәтләрен күрсәтеп рәсем ясарга өйрәтү.<br>• Кешенең тән | Шөгыль темасына кызыксыну уяту өчен, уен мизгелен кертеп җибәрү, балаларның милли киемнәр турындагы белемнәренә | А5 форматлы кәгазь бите, төсле карандашлар. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | төзелешен, әгъзалары формасын һәм зурлыгын рәсем аша җиткерә белүне ныгыту.<br>• Балаларны милли киемнәр, халык мәдәнияте үрнәкләре белән таныштыруны дәвам итү. | таянып, милли киемнәр турында сөйләү, төрле халыкларның милли киемнәре сурәтләрен карау, куллар-ның симметрияле хәрәкәтләре рәсемнәрен күрсәтү. | |
| **Декабрь. 1 нче атна** | | | |
| **43. Рәсем шау: «Табышмак хат».** | • Балаларны кеше фигурасын таяну сызыклары (чертоног) буенча рәсемгә төшерүнең яңа техникасы белән таныштыру.<br>• Хәрәкәтләрне рәсем аша күрсәтә белүләрен ныгыту.<br>• Илебездә яшәүче халыкларга толерант-лы мөнәсәбәт тәрбияләү. | Сюрприз мизгеле, биремне аңлату, үрнәкне күзәтү, өстәмә сораулар бирү, таяну сызыклары белән ясалган кеше фигурасын «киендерү» ысулларын күрсәтү. | Чертоноглар ясалган А4 форматлы кәгазь бите, төсле карандашлар. |
| **44. Әвәләп ясау: «Балалары белән песи».** | • Төрле зурлыктагы предметларны әвәләп ясарга һәм аларны гомуми композициягә берләштерергә өйрәтү.<br>• Ясалачак образ өслеген шомартып, катнаш ысул белән әвәләп ясый белүне ныгыту.<br>• Йорт хайваннарына мәхәббәт һәм сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү. | Үрнәкләрне карау, әвәләп ясау алымнарын күрсәтү, уен мизгеле, эшчәнлекне бәяләү. | Балчык яки пластилин, әвәләп ясау өчен такталар, салфеткалар, сыгылмалы таякчык, иллюстрацияләр. |
| **45. Рәсем ясау: «Кышкы урман» (гадәти булмаган эш алымнары).** | • Балаларның иҗади фантазияләрен үстерү өчен, аларны төрле предметлар (гадәти булмаган эш алымнары) ярдәмендә сурәтләү мөмкинлекләре белән таныштыруны дәвам итү.<br>• Агач һәм куак сурәтләрен таякчыктан өреп ясарга өйрәтү.<br>• Нәфасәти кабул итүне үстерү: балалар игътибарын төрле ел фасылларында туган як табигате гүзәллегенә юнәлтү. | Кышкы табигатькә соклану хисләре уяту, иллюстрацияләр карау, буяу табыннан өреп сурәт ясау ысулын күрсәтү, иҗади омтылышларны хуплау, бәяләү. | А4 форматлы кәгазь бите, су белән сыекландырылган кара һәм күрән төстәге гуашь, пумала, коктейль таякчыгы, салфеткалар, сулы банка, иллюстрацияләр, үрнәк рәсем. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **46. Кәгазьдән кору: «Биек һәм тәбәнәк чыршылар».** | • Квадрат кәгазь битен, якларын һәм почмакларын туры китереп, диагональ буенча бөкләргә өйрәтү.<br>• Эшләнмәне ясаганда, бөкләү этапларын планлаштыра белүгә ирешү.<br>• Нәфасәти бәяләүне формалаштыру. | Якынлашып килүче бәйрәм турында әңгәмә кору. Дөньядагы күп халыклар тарафыннан билгеләп үтелә торган Яңа елны каршылау бәйрәменә куану хисләре уяту, төркем бүлмәсен бизәү вариантлары турында сөйләшү; бизәлгән кәгазь чыршылар үрнәкләрен карау, аларны ничек ясарга икәнен күрсәтеп аңлату, эшләнмәне бөкләп ясау этаплары буенча сораулар бирү. Индивидуаль эш, контроль, бәяләү. | Оригинал өчен 15х15 см лы яшел кәгазь битләре, 10х10 һәм 12х12 см лы кәгазьләр - биек чыршылар өчен; 8х8, 6х6 см лы кәгазьләр - тәбәнәк чыршылар өчен. Җете төстәге кәгазьләр һәм фольга кисәкләре салынган «иҗат тартмасы», җилем, пумала, җепләр һәм фон өчен А4 форматлы кәгазь. |
| **Декабрь. 2 нче атна** | | | |
| **47. Рәсем ясау: «Суык бизәкләр төшергән».** | • Дулкынлы сызыклар, бормалы-сырмалы бөтеркәләр һәм кар бөртекләрен пумала очын җиңел һәм салмак йөртеп рәсем төшерергә күнектерү, шөгыль темасына карата үз хис-тойгыларыңны җиткерә белергә өйрәтү.<br>• Рәсемне кыш бизәкләреннән гыйбарәт рама белән бизәгәндә, дизайнерлык күнекмәләрен үстерү, төп сурәтне үзәккә урнаштыра белүгә ирешү. | Иллюстрацияләр карап, музыкаль әсәрләр тыңлап, эш алымнарын күрсәтеп, балаларда кыш бизәкләре турында күзаллау тудыру. Нәфис сүз һәм музыкаль әсәр тыңлау аша эшкә кызыксыну уяту. | А4 форматлы караңгы соры (зәңгәр) төстәге кәгазь, пумала, гуашь, салфеткалар, сулы банка, иллюстрацияләр. |
| **48. Кисеп ябыштыру: «Кыш бабайга хатлар стенды» (күмәк эш).** | • Үзәк аша берничә кат бөкләнгән кәгазьдән кар бөртекләре кисеп ясарга өйрәтү.<br>• Стенд рамкасын кар бөртекләреннән (зурлыклары, төсләре буенча аралаштырып) ясау.<br>• Үз гамәлләреңне партнерларың гамәлләре белән килештереп эшләргә өйрәтү. | Дөньяның күп халыклары тарафыннан билгеләп үтелүче Яңа елны каршылау бәйрәме якынлашуы турында искә төшерү. Кыш бабайга хатлар язу өчен стенд ясарга кирәклеген төшендерү. Квадратны үзәк аша берничә кат бөкләү тәртибен, кар бөртекләрен кисеп ясау вариантларын күрсәтү. | Төрле зурлыктагы ачык тондагы квадратлар, җилем, җилем пумаласы, клеенкалар, салфеткалар, А1 форматлы куе зәңгәр төстәге тыгыз кәгазь яки картон (фон өчен). |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **49. Иң яхшы рәсемгә конкурс: «Кыш бабай, Дед Мороз, Санта-Клаус резиденцияләре».** | • Балаларны бирем шартлары буенча рәсем ясарга өйрәтү.<br>• Әкияти йортлар рәсемен ясаганда, балаларның шәһәр һәм авыл биналарын ясау күнекмәләрен ныгыту.<br>• Балаларның иҗади фантазияләрен үстерү, үз эшләрен һәм башка балалар эшләрен объектив бәяләүләренә ирешү. | Эшкә этәрү өчен уенлы бирем. Балаларда күзаллау тудыру өчен, бирем турында әңгәмә кору. Яңа ел бәйрәменең төп геройлары, аларның охшаш һәм аермалы сыйфатлары турында сөйләү. | А4 форматлы кәгазь бите, төсле карандашлар яки акбурлар. |
| **Декабрь. 3 нче атна** | | | |
| **50. Рәсем ясау: «Яңа ел костюмы».** | • Алдан уйланган образны гәүдәләндереп, кеше фигурасы рәсемен ясарга өйрәтүне дәвам итү.<br>• Карандашны йомшак кына басып, рәсемне өстән-өстән генә сызгалап чыгу күнекмәсен ныгыту.<br>• Иҗади омтылышларны, фантазияләрне, якыннарны сөендерү теләкләрен үстерү | Рәсем эчтәлеген билгеләү өчен, әңгәмә үткәрү. Кеше фигурасын һәм аны «киендерүне» сызгалап күрсәтү. Индивидуаль ярдәм, иҗади омтылышларны бәяләү. | А5 форматлы кәгазь бите, төсле карандашлар яки акбурлар. |
| **51. Күмәкләшеп әвәләп ясау: «Кышкы уеннар».** | • Әвәләп ясауның таныш алымнарыннан иң уңайларын, иң кулайларын кулланырга өйрәтү.<br>• Сурәтне детальләр (башлык, бияләйләр, бизәкләр) белән баетып, берничә предметны гомуми композициягә берләштерү күнекмәсен ныгыту.<br>• Күмәкләп эшләү күнекмәләрен үстерү. | Уенлы бирем аша эшчәнлеккә тарту: дуска фотохат җибәрү, иллюстрацияләр карап, эш ысулларын сөйләшеп хәл итү, әвәләп ясау алымнарын өлешчә күрсәтү. Әвәләп ясау барышында индивидуаль ярдәм, эшчәнлеккә уен алымы белән анализ ясау. | Пластилин, әвәләп ясау такталары, иллюстрацияләр, картон аскуймалар, салфеткалар. |
| **52. Рәсем ясау: «Чыршы ботагы».** | • Ылысларны ясаганда, штрихлау төрләреннән файдаланырга өйрәтү.<br>• Ботаклар юнәлешен, ылысларны, төс төсмерләрен натурадан карап ясау күнекмәләрен ныгыту. | Чыршы ботагын җентекләп өйрәнү, нәфис сүз аша нәфасәти хисләр үстерү, карандаш белән эшләү алымнарын өлешчә күрсәтү. | А4 форматлы ак кәгазьнең яртысы, карандашлар, чыршы ботагы. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | • Туган як табигатенә соклану хисе уятып, әйләнә-тирә дөньяны нәфасәти кабул итүне үстерү. | | |
| **53. «Лето» конструк-торыннан кору: «Сарайлар».** | • Бер үк объектны төрле зурлыкта һәм төрле рәвештә кора белүгә ирешү.<br>• Детальләрне дөрес итеп урнаштырып, нык корылма ясау күнекмәсен ныгыту.<br>• Фикер йөртү, сөйләү, проектлар презентацияләү күнекмәләрен үстерү. Балаларда проект авторы турында күзаллау формалаштыру. | Уен алымы, фотосурәтләр карау, үрнәкне җентекләп карау-өйрәнү, аңлатып күрсәтә бару, проектлар презентацияләрен оештыру. | Һәр бала өчен «Лего» җыелмалары яки башка конструкторлар. |
| **Декабрь.4 нче атна** | | | |
| **54. Рәсем ясау: «Чыршы уенчыгы» (пыяла лампочкаларга, флаконнарга, кечкенә шешәләргә бизәк төшерү).** | • Балаларны ташландык материалга куллану табарга өйрәтү, пыялага бизәк төшерү үзенчәлекләре белән таныштыру. Буяулар тактасын (палитраны) буяуларны ждлем белән кушу өчен куллануны хуплау.<br>• Уенчыкта ясалачак бизәкне үзең уйлап табарга һәм аны пыяла өслеккә төшерергә өйрәнү. Буяулар белән ясауның таныш алымнарын (пумала белән, баскалап, чәчрәтеп) куллану күнекмәләрен ныгыту.<br>• Иҗади эшләүләрен, фантазияләрен, якыннарны сөендерү теләген үстерү. | Уенлы бирем аша эшчәнлеккә этәрү. Эш эчтәлеген билгеләү өчен, иллюстрацияләр карап, әңгәмә үткәрү. Буяулар белән рәсем ясауның төрле алымнарын кулланып күрсәтү. Индивидуаль ярдәм, балаларның иҗади омтылышын хуплау, бәя бирү. | Пыяла предметлар (лампочкалар, буш кечкенә шешәләр, флаконнар), гуашь, җилем, пумала, буяулар тактасы, салфеткалар, сулы банка, иллюстрацияләр. |
| **55. Кисеп ябыштыру: «Яңа ел открыткасы».** | • Күләмле, панорама рәвешендәге сюрпризлы открыткалар әзерләргә өйрәтү.<br>• Симметрияле итеп кисү осталыгын ныгыту.<br>• Яңа ел бәйрәме - уртак шатлыклы чарага әзерлек вакытында һәр баланы катнаштырып, алар да үзләренең кирәклекләрен тою хисе уяту. | Эшне алдан күзаллау өчен, нәфис сүз куллану. Эшләү алымнарын аңлату һәм өлешчә күрсәтү, контроль, хуплау һәм мактау, эшчәнлекләренә бәя бирү. | А4 форматлы төрле төсләрдәге кәгазь бите, җилем, җилем өчен пумалалар, клеенкалар (һәр балага), төрле предметлар кисү өчен әзерләмәләр. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **56. Граттаж техникасы белән рәсем ясау: «Умка».** | • Ю. Я. Яковлевның «Умка» әсәрен уку, рәсем ясауның яңа техникасы граттаж (тырнап-тырнап) белән таныштыру.<br>• Илебез табигатенең күптөрлелеге, төрле климат зоналарында яшәүче хайваннар һәм үсемлекләр турындагы белемнәрне киңәйтү.<br>• Алгы, урта, ерак пландагы предметларны сурәтләгәндә, композиция төзү осталыгын үстерү. | «Умка» экиятен уку һәм мультфильмын карау. Граттаж техникасы белән эшләү өчен, шөгыльгә кадәр үк нигез әзерләп кую. Әсәрдә сурәтләнгән климат зонасын һәм анда яшәүчеләрне искә төшереп әйттерү. Балаларның рәсемне ничек ясаячаклары, нинди композиция төзергә теләүләре турында сөйләшеп алу. Рәсем ясауның яңа техникасын өлешчә эшләп күрсәтү. Алгы, урта, арткы пландагы предметларның сурәтләрен ничек ясауларын карап, шул турыда сөйләшү. | Граттаж өчен алдан әзерләп куелган нигез, тырнау өчен таякчык (теш чистарткычлар), кайчы, җилем, аю баласы гәүдәсе өчен әзерләмә, салфеткалар, пумала, аскуйма. |
| **Гыйнвар. 3 нче атна** | | | |
| **57. Күмер белән рәсем ясау: «Кышкы экият».** | • Балаларны күмер белән рәсем ясау техникасы, аның сурәтләү мөмкинлекләре белән таныштыру.<br>• Рәсем сюжетын һәм аны ничек сурәтләүне балаларның үзләреннән уйлатып, аларның иҗади омтылышларын көчәйтү.<br>• Сурәтләү эшчәнлегендә төрле материаллар кулланып, балаларның кызыксынуларын, белемнәрен арттыру. | Яңа сурәтләү материалының мөмкинлекләрен (штрихлау, күләгәләү, контурлар сызу яки күләмне җиткерү) күрсәтеп, аның белән кызыксыну уяту. Нәфис сүз аша шөгыль темасына нәфасәти мөнәсәбәт булдыру. Эш нәтиҗәләрен күреп соклану, аларга бергәләп бәя бирү. | А4 форматлы кәгазь бите, әзерләнгән күмер, салфеткалар. |
| **58. Әвәләп ясау: «Кунаклар көтәбез».** | • Пластилинны тасма рәвешендә сузып, чынаяк ясарга, аның формасын һәм төп өлешләре пропорциясен дөрес итеп җиткерә белергә өйрәтү.<br>• Өслекне тигезләү, шомарту алымнарын ныгыту.<br>• Кунакчыллык тәрбияләү, тормышның билгеле бер ситуацияләрендә үз-үзеңне | Кунакчыллык йоласы турында сөйләшү, тасма рәвешендә әвәләп ясау алымнарын күрсәтү, өслекне тигезләү, шомарту алымнарын искә төшерү. Әвәләп ясау барышында индивидуаль ярдәм, әзер эшләрнең иң | Пластилин яки балчык, әвәләп ясау өчен такталар, салфеткалар, сыгылмалы таякчык, мөһерләр (басып сурәт төшерү өчен). |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | тоту кагыйдәләре һәм нормалары кысаларында эш итәргә күнектерү. | яхшыларын аерым бәяләп үтү. | |
| **59. Рәсем ясау: «Кыш бабай һәм Кар кызы».** | • Кыш бабай һәм Кар кызының әкияти образларын рәсем аша җиткерергә өйрәтүне дәвам итү, предметларның зурлыклары буенча аермаларына, өлешләре пропорцияләренә игътибар юнәлтү.<br>• Фигураларның хәрәкәтләрен рәсемдә күрсәтү күнекмәсен ныгыту.<br>• Рәсемне тулыландырганда һәм шуның буенча хикәя төзегәндә, иҗади сәләтләр ачылуга этәрү. | Яңа елны бәйрәм итү, бәйрәмнең төп персонажлары турында сөйләшү. Кыш бабай, Кар кызы рәсемнәрен карау, аларның зурлыклары, гәүдә өлешләре пропорцияләре аермаларын табу. Фигуралар хәрәкәтләрен рәсемгә төшерү алымнарын өлешчә ясап күрсәтү. | А4 форматлы кәгазь бите, пумалалар, акварель буяулар, салфеткалар, сулы банка, Кыш бабай һәм Кар кызы рәсемнәре. |
| **60. Кору: «Кояшлы шәһәр» (күмәк эш).** | • Балаларны күмәк эшләргә, кайсы эшне кем башкарасын үзара килешеп, үз корылмаларын алдан ниятләнгәнчә берләштерергә өйрәтү.<br>• Үз корылмаларын ничек төзергә икәнлеген һәм аны планлаштыру этапларын анализ нигезендә табу күнекмәсен ныгыту.<br>• Язучы Н. Носовның «Белмәмеш Кояшлы шәһәрдә» әсәренең өзекләрен укып фикер алышулар аша һәм күмәк хезмәт ярдәмендә балалар арасында дуслык мөнәсәбәтләре тәрбияләү. | «Незнайка в Солнечном городе» мультфильмы өзекләрен карап, һәм аның турында фикер алышып, биремне дәлилләү корылмаларын күзәтеп, шул хакта әңгәмә оештыру, эш эзлекле л еген аңлату, һәр балага эш бирү. | Һәр балага кору материаллары җыелмасы яки «Лето» конструкторы, вак уенчыклар, Н. Носовның «Белмәмеш Кояшлы шәһәрдә» әсәренә иллюстрацияләр. |
| **Гыйнвар. 4 нче атна** | | | |
| **61. Рәсем ясау: «Казлар-аккошлар».** | • Кошларның канат җилпеп очуларын киң буялыш аша җиткерә белергә өйрәтү.<br>• Кошлар гәүдәсе өлешләренең пропорциональ чагыштырмаларын пумала белән төрлечә буял (пумала | А. Н. Толстой эшкәртүендәге «Казлар-аккошлар» («Гуси-лебеди») рус халык әкиятенә ясалган иллюстрацияләрне карау, нәфис сүз | А4 форматлы соры (зәңгәр) төстәге кәгазь бите, пумалалар, ак гуашь, салфеткалар, сулы банка, «Казлар-аккошлар» |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | очы белән, пумаланы җәеп), рәсем аша җиткерә алу күнекмәсен ныгыту.<br>• А. Н. Толстой эшкәртүендәге «Казлар-аккошлар» («Гуси-лебеди») рус халык әкиятенә иллюстрацияләр ясау аша матур әдәбият белән кызыксынуны арттыру. | куллану, кошларның канат җилпеп очуларын киң буялыш аша күрсәтү, балалар эшләренә анализ ясау. | рус халык әкиятенә иллюстрацияләр. |
| **62. Кисеп ябыштыру: «Кар бөртек-ләре».** | • Үзәк аша берничә кат бөкләнгән кәгазьдән кар бөртекләре кисәргә өйрәтүне дәвам итү.<br>• Квадрат кәгазь битенең якларын һәм почмакларын тәңгәл китереп, төрле юнәлештә пөхтә итеп бөкләү күнекмәсен ныгыту.<br>• Кар бөртекләре бизәкләрен үзләре күзаллаганча ясатып, балаларның фантазияләрен үстерү. | Кар бөртекләре ясалган рәсемнәрне, үрнәкләрне, схемаларны җентекләп карау, күрсәтеп аңлата бару. Индивидуаль ярдәм, контроль, бәяләү. | Кар бөртекләре рәсем-нәре, схемалар, үрнәкләр, һәр бала өчен квадрат кәгазь битләре (өчәр). |
| **63. Рәсем ясау: «Кыш-лаучы кошлар».** | • Гади карандаш белән сызгалап рәсем төшерергә, туган ягыбызда кышлаган кошларга (карабүрекләр, песнәкләр, чыпчыклар, саесканнар) хас үзенчәлекле билгеләрне (каурыйлары, зурлыклары, гәүдә әгъзалары пропорцияләрен) рәсем аша Іҗиткерә белергә өйрәтү.<br>• Кошлар хәрәкәтләрен рәсем аша җиткерү күнекмәсен ныгыту.<br>• Туган як табигатен, тереклек дөньясын күзәтүчәнлекне үстерү. Кошларга, аеруча кыш айларында, кайгыртучан мөнәсәбәт тәрбияләү. | Карабүрек, песнәк, чыпчык, саескан сурәтләнгән иллюстрацияләрне җентекләп карау. Кошларны сурәтләү тәртибен күрсәтү (кошларның иң зур гәүдә әгъзаларыннан башлап гади карандаш белән сызгалап рәсем ясау). Кирәкле төсмерләрне китереп чыгару өчен, буяулар тактасында төсләрне кушу. Индивидуаль ярдәм. Ясалган кош турында хикәя төзеп анализ ясау. | А4 форматлы кәгазь бите, пумалалар, сулы банка, буяулар тактасы, кошлар рәсемнәре. |
| **Февраль. 1 нче атна** | | | |
| **64. Рәсем ясау: «Барыня».** | • Балаларны рус халкының декоратив-гамәли сәнгате белән таныштыруны дәвам итү. Дымково барынясына бизәк төшерү кагыйдәләре белән таныштыру, бердәй нокталар ясау өчен, бөтереп ишелгән | Дымково барыняларының (су ташучы, бала караучы, купшыбикә) итәк бизәкләре вариантларын, кокошнигы һәм итәге, | Барынялар силуэтлары, пумалалар, акварель буяулар, салфеткалар, сулы банка, палитра, иллюстрацияләр, Дымково барынялары бизәкләре схемасы. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | кәгазь белән басарга өйрәнү.<br>• Пумала белән төрле юнәлешләрдә буяу күнекмәсен ныгыту, төрле зурлыктагы пумалалар куллану осталыгын камилләштерү.<br>• Үзләре ясаган уенчыкларны караганда, балаларның нәфасәти кабул итүләрен үстерү. | төсләре ярашуын күзәтү-өйрәнү. Нәфис сүз куллану, бөтерелгән кәгазь белән басып рәсем төшерү алымын күрсәтү, киң һәм нечкә пумаланы эштә куллану. | |
| **65. Әвәләп ясау: «Федора кайгысы».** | • Балаларны балчык яки пластилинны тасма рәвешендә сузып, шуннан савытлар әвәләп ясарга өйрәтүне дәвам итү, шул эштә савыт өлешләренең пропорциональ чагыштырмасын күрсәтә белүләренә, детальләрне ялгап һәм сылап, өслекләрен шомартып эшләүләренә ирешү.<br>• Әвәләп ясауда кулай алымнарны сайлый белүләрен ныгыту, уйланган эшне ахырына җиткерүләренә ирешү.<br>• Кеше хәленә керә белү һәм рәхимлелек, әйберләргә сак мөнәсәбәт тәрбияләү. | К. И. Чуковскийның «Федорино горе» әкияте, башка шигырьләр һәм әкиятләрдән өзекләр уку, аларга ясалган иллюстрацияләрне карау, әвәләп ясау ысулларын күрсәтү. Балаларның мөстәкыйль эшләүләре. | Балчык яки пластилин, әвәләп ясау такталары, уенчык савыт-саба, салфеткалар. |
| **66. Алдан уйлап, рәсем ясау: «Зоопаркта нәрсә бар?»** | • Хайваннарның гәүдә формаларын, әгъзалары пропорцияләре чагыштырмасын үзең күзаллаганча алдан уйлап рәсем аша җиткерә белергә өйрәтү.<br>• Композиция төзү күнекмәләрен ныгыту, төрле климат зоналары хайваннарын аера белүгә ирешү.<br>• Хайваннарны сурәтләгәндә, рәсемне тулыландырганда иҗади омтылышларны хуплау. | Шөгыль темасы турында әңгәмә кору. Жираф, фил, арыслан һ. б. хайваннар рәсемнәрен һәм уенчыкларын җентекләп карау. Аларны рәсемгә төшерү алымнары турында фикер алышу. | Жираф, фил, арыслан һ. б. хайваннар рәсемнәре һәм уенчыклар. А4 форматлы кәгазь бите, пумалалар, гуашь, салфеткалар, сулы банка. |
| **67. Кәгазьдән кору: «Умыр-заялы кәззин».** | • Балаларны өлге буенча корырга (зур квадраттан 16 квадрат бөкләп куярга, бер рәт квадратны кисеп алып, өстән һәм астан кисеп ждгоәреп, ачык тартма ясарга) өйрәтү.<br>• Әзер эшләнмәне үзең күзаллаганча пластилиннан чәчәкләр ясап тулыландыру күнекмәсен ныгыту. | Балаларны шөгыль темасына җәлеп итү өчен, язучы С. Я. Маршакның «Двенадцать месяцев» әкияте сюжетын куллану. Үрнәк кәрзинне җентекләп карау, эшләү ысулларын күрсәтеп, | 20х20 см лы йомшак картон яки сыек тондагы тыгыз кәгазь, чәчәкләр ясау өчен пластилин, сабаклар өчен нәзек ботаклар яки теш чистарткыч, аскуйма, пумала, җилем, һәр балага салфеткалар. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | • Конструктив фикерләүне үстерү, өстәмә детальләрне сурәтләү ысулларын мөстә-кыйль уйлап табуга ирешү. | конструктив күнекмәләр формалаштыру. | |
| **Февраль. 2 нче атна** | | | |
| **68. Рәсем ясау: «Ә безнең тәрәзәбездән Кызыл мәйдан күренә...»** | • Балаларның композицион күнекмәләрен үстерү, сурәтләрне киң яссылыкта урнаштырырга, предметларның кайда урнашуларына карап (алгы, урта, арткы планда), аларның күләмнәре аермасын рәсем аша күрсәтә белергә өйрәтү.<br>• Ясарга ниятләгәнне сюжет аша җиткерә белү күнекмәләрен ныгыту. • Үз шәһәрләренә (авыл яки салаларына) карата мәхәббәт һәм горурлык хисләре тәрбияләү. | Шөгыль темасына якын килү максатында, С. Михалковның «А что у вас?» шигыре өзекләрен уку. Балаларның нәрсә ясарга ниятләүләре турында, сюжет сызыгын җентекле тасвирлап, әңгәмә оештыру. Предметларның кайда урнашуларына карап (алгы, урта, арткы планда), күләмнәре аермасын рәсем аша күрсәтү кагыйдәләрен үтәүләренә анализ ясау. | Төсле карандашлар (акбурлар, фломастерлар), альбом бите, сюжетлы иллюстрацияләр. |
| **69. Кисеп ябыштыру: «Күңелле әйлән-бәйлән».** | • Гармун күрегедәй итеп берничә кат бөкләнгән кәгазьне кисү алымын өйрәтү.<br>• Материалларга сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү.<br>• Эшләнмәне өстәмә детальләр белән тулыландыруда мөстәкыйльлекне үстерү. | Әйлән-бәйлән иллюстрацияләрен карау, үрнәкне күзәтү, тулысынча аңлатып эшләп күрсәтү, һәр балага ярдәм итү. Контроль, балаларның дөрес эшләүләрен бәяләү һәм иҗади омтылышларын хуплау. | Әйлән-бәйлән иллюстрацияләре, буйга урталай бүленгән А4 форматлы кәгазь бите, җилем, җилем пумалалары, һәр бала өчен клеёнка, төрле төстәге һәм фактурадагы кәгазь кисәкләре салынган «иҗат тартмасы». |
| **70. Рәсем ясау (кисеп ябыштыру элемент-лары белән): «Валентинка».** | • Хохлома бизәкләре һәм татар орнаменты үрнәкләренә карап, симметрияле формада бизәкләр төзергә өйрәтүне дәвам итү.<br>• Симметрияле итеп кисү (турыпочмаклы кәгазь битенең почмакларын һәм якларын тәңгәл китереп бөкләү, кискәндә бөкләү сызыгыннан тотып тору) күнекмәләрен ныгыту.<br>• Бизәкне формада урнаштыру ысулын сайлаганда, композицияне тоемлау хисен үстерү. | Йөрәк формасындагы открыткаларны, хохлома бизәкләре, татар орнаменты элементларын җентекләп күзәтү, бизәк элементларын урнаштыру вариантлары турында әңгәмә кору, төрле элементларны рәсемдә ясау алымнарын искә төшерү. | А4 форматлы кызыл, сары төстәге кәгазь битләре, гуашь, нечкә пумала, сулы банка, аскуйма, салфетка, кайчы, йөрәк формасындагы открыткалар, хохлома бизәкләре һәм татар орнаменты элементлары. |
| **Февраль. 3 нче атна** | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **71. Рәсем ясау: «Кышкы урман» (тал төшерү, таякчык белән өрү).** | • Балаларны рәсем ясауның төрле техникалары (тап төшерү, таякчык белән өрү) белән таныштыруны дәвам итү.<br>• Балаларның композиция төзү күнекмәләрен ныгытырга, сурәтләрне предметларның кайда урнашуларына карап (алда, уртада, арткы планда), аларның күләмнәре аермасын күрсәтеп урнаштырырга өйрәтү.<br>• Иҗади фантазияләрен, кызыксынучанлыкларын, пөхтәлекләрен үстерү. | Кыш турында әңгәмә оештыру, иллюстрацияләр карау. Эш материалларын күрсәтеп, балаларның агачлар ясаганда кәгазь битенә пумала белән тап төшереп, аны таякчык белән өрү алымын, алгы һәм арткы пландагы предметларны сурәтләү кагыйдәләрен искә | А4 форматлы кәгазь бите, гуашь яки акварель, нечкә пумала, сулы банка, аскуйма, салфетка, коктейль таякчыгы, алда әйтеп үтелгән рәссамнар картиналарына иллю-страцияләр. |
| **72. Әвәләп ясау: «Хәрби танклар».** | • Танк өлешләрен (корпус, түбәсе, тубы (пушкасы), пулеметы, командир люгы, тәгәрмәч чылбыры, тәгәрмәчләре) ныклап ялгап ясарга өйрәтүне дәвам итү.<br>• Предметның кайбер өлешләрен сыгылмалы таякчык белән ясау күнекмәсен формалаштыруны дәвам итү.<br>• Россия Хәрби көчләре турында күзаллауларны киңәйтү. | Язучы Н. Иванованың «Танкист» шигырен уку, танк өлешләрен ясау ысулларын бергәләп хәл итү. Әвәләп ясаганда өлешләрне ялгау, өслекне тигезләү, эшне сыгылмалы таякчык белән формалаштыру ысулларын өлешчә эшләп күрсәтү. | Пластилин, такта, салфетка, сыгылмалы таякчык. |
| **73. Рәсем ясау: «Китап бите кыстыргычы».** | • Балаларны Россия халыкларының декоратив-гамәли сәнгате үрнәкләре (Городец бизәге) белән таныштыруны дәвам итү.<br>• Бизәкне озынча яссылыкта (полосада) урнаштыру күнекмәсен ныгыту.<br>• Халык осталары эшләнмәләрен күреп соклана белүне үстерергә, чәчәк бәйләмнәре төсләре, формалары ярашу гүзәллеген күрергә өйрәтү. Халык иҗатына карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. | Балаларны Городец бизәкләре төшерелгән предметлар белән таныштыру. Шигырь сөйләп, шөгыль темасына якынайту. Городец бизәкләре төшерелгән иллюстрацияләр карау, эш алымнарын тулысынча эшләп күрсәтү. | Гуашь, сары төстәге А4 форматлы кәгазьнең яртысы, уртача һәм нечкә пумала, салфеткалар, сулы банка, Городец бизәкләре тө-шерелгән иллюстрацияләр һәм предмелар. |
| **74. Цилиндр рәвешенә китерелгән кәгазьдән кору: «Кыргый хайван-нар».** | • Балаларны әзер өлге буенча эшләргә (турыпочмаклы тыгыз кәгазьне цилиндр рәвешендә) төрергә һәм | Нәфис сүз куллану. Үрнәк уенчыкларны җентекләп карау, формаларын ачыклау, | Үрнәк уенчыклар, уен-чык өлгесе ясалган А4 форматлы кәгазь |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ябыштырырга, детальләрдән җәнлек сынын төзергә өйрәтергә.<br>• Формаларны салмак кисеп ясауга күнектерү.<br>• Образлы фикерләүне үстерү. | аларның ясалу ысулын хәл итү. Эшләп күрсәтү, балаларга ярдәм итү, хуплау. | бите, кәгазь әзерләмәләр, җилем, җилем пума-ласы, һәр балага салфеткалар. |
| **Февраль. 4 нче атна** | | | |
| **75. Рәсем ясау: «Куәтле армиябез».** | • Балаларны махсус транспорт өлешләренең чагыштырмача зурлыкларын һәм пропорцияләре чагыштырмаларын рәсемдә күрсәтеп тасвирларга өйрәтү.<br>• Сайлап алынган техника предметына мөстәкыйль анализ ясау күнекмәсен ныгыту.<br>• Россия армиясенә, Ватанны саклаучы хәрбиләргә хөрмәт хисе тәрбияләү. | Нәфис сүз куллану, хәрби темага уенчыклар, иллюстрацияләр күрсәтү, аларны бергәләп карау, биремне мөстәкыйль үтәү. Индивидуаль ярдәм. Эшләргә анализ ясау. | Төсле карандашлар, альбом бите, уенчыклар, хәрби техника рәсемнәре. |
| **76. Кисеп ябыштыру: «Кораблар, пароходлар».** | • Кораб өлешенең формасына карап, кисүнең төрле алымнарын кулланырга өйрәтүне дәвам итү.<br>• Кайчы белән салмак кисү техникасын ныгыту.<br>• Сурәтне образлы бәяләүгә этәрү. Б. Заходерның «Если мне подарят лодку» шигыре белән таныштыру. | «В порту» мультфильмыннан өзек карау. Б. Заходерның «Если мне подарят лодку» шигырен уку аша шөгыль темасы белән кызыксыну уяту. Кораб төрләре, аларны хәрәкәткә китерү ысуллары турында әңгәмә кору. Җилкәнле кораб, пароход, катер һ. б. рәсемнәрен (зурлыклары, төсләре, өлешләренең урнашуы) карау. Эшләү алымнарын бергәләп хәл итү. | Кораб рәсемнәре, кайчы, җилем, салфеткалар, А4 форматлы зәңгәр кәгазь бите, кораб корпусы өчен 15х6 см лы турыпочмаклы төрле төсләрдәге кәгазь, палубалар өчен 13х2, 11х2, 9х2 см лы төрле төсләрдәге турыпочмаклы кәгазьләр, җилкәннәр өчен 11х6, 7х4 см лы турыпочмаклы кәгазьләр, төрле төстәге һәм фактурадагы кәгазь кисәкләре салынган «иҗат тартмасы». |
| **77. Рәсем ясау: «Хохлома подносы».** | • Хохлома бизәкләре элементлары кулланып, түгәрәк кәгазь битендә сурәт ясарга өйрәтү, пумала белән ясауны (сабаклар, яфраклар, чәчәкләр) мамык таякчыклар белән баскалау (җиләкләр) ысуллары белән аралаштырырга эшләү. | Балалар тәҗрибәсен арттыруга юнәлтелгән сораулар бирү. Хохлома поднослары үрнәкләрен (бизәк урыны, элементлары, төсләр ярашуы) бергәләп карау-өйрәнү, | 10 см радиуслы кара төстәге түгәрәк тыгыз кәгазь, сары, кызыл һәм яшел төстәге гуашь, пумалалар, аскуйма, су, салфетка, мамык таякчык. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | • Гуашь, нәзек пумала белән эшләү күнекмәләрен, туган як үсемлекләре турындагы белемнәрне ныгыту.<br>• Нәфасәти кабул итүне үстерү. | сурәтләрнең аерым элементларын үзара яраштырып тоташтыру алымнарын аңлата барып, өлешчә ясап күрсәтү. | |
| **Март. 1 нче атна** | | | |
| **78. Рәсем ясау: «Әниемә Городец тактачыгы».** | • Агач тактага, формасына туры китереп, Городец бизәге төшерергә өйрәтү.<br>• Балаларның композиция ясау күнекмәләрен үстерүне дәвам итү һәм бизәкләрнең таныш элементларын мөстәкыйль кулланударына ирешү.<br>• Якыннарының күңелләрен күрү теләге уяту, аларга игътибар тәрбияләү. | Алда көтелгән бәйрәм (8 Март) турында әңгәмә үткәрү, Городец бизәкләре турында күзаллау тудыру өчен, шигырьләр уку, иллюстрацияләр карау, бизәкләрне аңлату; эш барышында ярдәм итү. | Эшкәртү тактасы, нечкә һәм уртача пумала, гуашь, салфеткалар, сулы банка, Городец бизәкләре элементларыннан гыйбарәт иллюстрацияләр. |
| **79. Әвәләп ясау: «Чынаяк кирпеч».** | • Халык иҗаты белән таныштыруны дәвам итү. Рус халык чынаяк кирпечләренә (кафель) охшатып, декоратив пластиналар ясарга өйрәтү.<br>• Ниятләнгән эшкә туры килә торган әвәләп ясау алымнарын сайлап ала белү күнекмәсен ныгыту.<br>• Эш эчтәлеген сайлауда мөстәкыйльлекне үстерү. | Тәрбияче әңгәмә үткәреп, табышмаклар әйтеп, чынаяк кирпеч иллюстрацияләрен карап, ясалачак эшләнмә эчтәлегенә анализ ясый, үзе эшләп күрсәтә. | Балчык, тактачык, сулы савыт, пумала, салфетка, сыгылмалы таякчык, чынаяк кирпеч иллюстрацияләре» |
| **80. Рәсем ясау: «Песиле тал ботагы».** | • Песиле тал ботагын натурадан карап ясарга өйрәнү, рәсемдә аның урнашу үзенчәлекләрен күрсәтү, тиешле төсмерләр табу өчен төсләр кушу.<br>• Төрле калынлыктагы пумалаларны куллану күнекмәләрен ныгыту.<br>• Балаларның композиция ясау күнекмәләрен үстерү. | Иллюстрацияләр карау, песиле тал үрентеләрен ясаганда буяулар кушу, уртача һәм киң пумала белән ясау алымнарын тулысынча эшләп күрсәтү, нәфис сүз куллану, аңлата бару. | Гуашь, киң, уртача һәм нечкә пумалалар, сулы банка, салфетка, А4 форматлы кәгазь бите, вазага куелган песиле тал ботагы. |
| **81. Табигый материалдан кору: «Чәчәкләр белән бизәлгән рам».** | • Табигый материал кулланып бизәү элементлары белән таныштыруны дәвам итү.<br>• Бизәк элементларын турыпочмаклыкның почмакларына, ян-якларына, капмакаршы почмакларына урнаштыру күнекмәсен ныгыту.<br>• Мөстәкыйльлекне, иҗади күзаллауларны үстерү. | Фоторамалар һәм аларның бизәкләрен җентекләп карау, бизәү алымнарын күрсәтү, балалар ясаган үзенчәлекле эшләргә, аларның матурлыгына соклану, анализ ясау. | Орлыклар һәм каурыйлы орлыклар, төрле төстәге пластилиннар, фотографияләр өчен төсле картоннан киселгән рам. |

| Март. 2 нче атна | | | |
|---|---|---|---|
| **82. Рәсем ясау: «Март ишек төбендә».** | • Балаларны дымлы кәгазь битендә акварель буяулар кулланып рәсем ясау алымы белән таныштыруны дәвам итү.<br>• Якын һәм ерак пландагы предметларны сурәтләү күнекмәсе формалаштыруны дәвам итү.<br>• Алдан уйлап эшләү күнекмәсе булдыру өчен, табигатьтә ел фасылларының үзгәреп торуы турында күзаллау формалаштыру. | Балалар бакчасы участогында табигатьне күзәтү, табигать күренешләре иллюстрацияләре карау: М. Х. Аладжалов. «Авылда яз»; Р. А. Берггольц. «Гатчинада җепшек көн»; И. И. Бродский. «Яз»; Ә. Мәҗитов. «Апрель»; Ю. А. Левицкий. «Умырзаялар»; А. И. Куинджи. «Каен урманы»; И. С. Остроухов. «Иртә яз»; П. Сезанн. «Фонтенбло урманында җепшек кар». Балаларның нәрсә ясарга уйлаулары турында сөйләшеп алу, дымлы кәгазьдә акварель буяулар белән рәсем ясап күрсәтү. | Акварель буяулар, киң, уртача һәм нечкә пумалалар, сулы банка, салфетка, А4 форматлы кәгазь, алда санап үтелгән рәссамнар картиналарына иллюстрацияләр. |
| **83. Кисеп ябыштыру: «Гөлләрем-чәчәкләрем».** | • Үзәк аша берничә кат бөкләнгән кәгазьдән чәчәкләр кисәргә өйрәтүне дәвам итү.<br>• Чәчәк бәйләме ясап, композиция төзү күнекмәләрен ныгыту.<br>• Урта полосадагы үсемлекләр дөньясы белән таныштырып, нәфасәти кабул итүне үстерү. | Шөгыль темасына кызыксыну уяту өчен, шигырьләр уку, иллюстрацияләр карау, кисү алымнарын күрсәтү. Балалар ясаган эшләрне бергәләп карау, бәя бирү. | Төрле зурлыктагы квадрат төсле кәгазьләр, җилем, пумала, клеенка, А4 форматлы ачык төстәге кәгазь бите, сабаклар һәм яфраклар ясау өчен фломастерлар/каран дашлар. |
| **84. Рәсем ясау: «Әнием портреты».** | • Балаларны портрет жанры белән таныштыру.<br>• Кеше йөзенә хас билгеләрне (формасы, төсе, күз уемы, чәч рәвеше) рәсем аша күрсәтә белергә өйрәтүне дәвам итү.<br>• Иң кадерле һәм иң якын кеше буларак анага карата мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләү, балаларның аңа игътибарлы, ихтирамлы булуларына ирешү. | Ә. Мәҗитовның «Дымково уенчыгын ясаучы Безденежных портреты», Ф.К. Винтерхальтерның «Императрица Мария Александровна портреты»н, А. ван Дейкның «Карла I нең өч баласы» картиналарына иллюстрацияләрне карау. Балаларга портрет ясау алымнарын күрсәтү, аңлату. Нәфис сүз куллану. | Акварель буяулар, киң, уртача һәм нечкә пумала, сулы банка, салфетка, А4, форматлы кәгазь, портретлар иллюстрацияләре. |

| Март. 3 нче атна | | | |
|---|---|---|---|
| **85. Рәсем ясау: В. Бианкиның «Куыш» әсәре буенча.** | • Балаларны төрле материалларның (күмер) сурәтләү мөмкинлекләре белән таныштыруны дәвам итү.<br>• Корылмалар пропорцияләрен, хайваннарның үзенчәлекләрен рәсем аша җиткерә белү күнекмәләрен ныгыту.<br>• В. Бианкиның «Куыш» әкияте белән танышу аша балаларда хайваннар тормышына, аларның яшәү тирәлегенә, үзара мөнәсәбәтләренә кызыксыну уяту. | В. Бианкиның «Теремок» («Куыш») әкиятенә Е. Чарушин иллюстрацияләрен карау, сурәтләү ысулы, график материаллар турында сораулар бирү; корылмага, аның өлешләре пропорция-ләренә, хайваннар үзенчәлекләренә игътибар юнәлтү; күмер белән рәсем ясау алымнарын күрсәтү - күмер кисәгенә басу көчен көйләп, штрихлар сызарга һәм ноктилар төртергә (күләмне, фактураны күрсәтергә өйрәтү). | Әзерләп куелган күмер, дымлы салфетка, А4 форматлы ачык төстәге кәгазь бите, В. Бианкиның «Куыш» әкиятенә Е. Чарушин ясаган иллюстрацияләр. |
| **86. Әвәләп ясау: «Кувшин».** | • Балаларны савыт-саба ясауның әйләнмәле сылау кебек яңа ысулы белән таныштыру.<br>• Алдан уйлап куелган форманы ясау күнекмәсен ныгыту.<br>• Балаларның нәфасәти карашларын киңәйтү өчен, дөнья халыкларының балчык савыт-сабалары (керамика) белән таныштыру. | Татар, украин һ. б. халыкларның балчык кув-шиннары, тар муенлы чүлмәкләре һ. б. Керам-ик савыт-саба иллюстрацияләрен җентекләп карау, нинди материалдан ясалулары, аларны ясау ысуллары турында әңгәмә кору; савыт-саба ясауның әйләнмәле сылау ысулын күрсәтү; балаларның үз эшләнмәләре турында сөйләшү. | Балчык, такта, сулы савыт, пумала, салфетка, сыгылмалы таякчык, төрле ха-лыкларның керамик савытлары иллюстрацияләре. |
| **87. Рәсем ясау: «Тәүге чәчәкләр».** | • Рәсем ясаганда төрле сурәтләү материалларын (балавыз, акбурлар, акварель буяулар) куллана белү.<br>• Композиция ясау күнекмәләрен формалаштыруны дәвам итү.<br>• Балаларны туган якның тәүге чәчәкләре белән таныштыру. | Шөгыль темасына карата кызыксыну уяту өчен нәфис сүз куллану, иллюстрацияләр карау: Ю. А. Левицкий. «Умырзаялар»; О. Ренуар. «Яз чәчәкләре бәйләме»; кайбер чәчәк рәсемнәрен ясау ысулларын күрсәтү. | Балавыз акбурлар, ак-варель, пумала, салфетка, сулы савыт, пумала куйгыч, А4 форматлы кәгазь бите. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **88. Кәгазьдән кору: «Парашют».** | • Конус рәвешенә китерелгән кәгазьдән күләмле уенчыклар ясарга өйрәтү.<br>• Эшләнмәне формасына карап бизәү күнекмәсен ныгыту.<br>• Балаларны уенда аралашуга этәрү. | Парашют ясалган иллюстрацияләрне карау, әзер парашют үрнәген күзәтү, түгәрәк кәгазьдән бөтереп конус ясауны, тоташкан урыннарны ябыштыруны, парашют арканнарын бәйләп яки ябыштырып куюны күрсәтеп аңлата бару. | Түгәрәкне бизәү кагый-дәләрен искә төшерү. Парашют сурәтләнгән рәсемнәр, радиус бу-енча кисү сызыгы ясалган түгәрәк, парашютны бизәү өчен әзерләмәләр. |
| **Март. 4 нче атна** | | | |
| **89. Рәсем ясау: «Нәүрүз».** | • Балаларны үзләре күзаллаган яз образын рәсемдә күрсәтергә өйрәтү.<br>• Кеше сынын пропорциональ сурәтләү күнекмәсен ныгыту.<br>• Табигатьтә яз көне күзәтелгән үзгәрешне күреп соклана белергә өйрәтү. | Тәрбияче, яз турында әңгәмә үткәреп, балаларны шөгыль темасы белән кызыксындыра. Язны каршылау - «Нәүрүз» бәйрәме турында сөйли, балаларның язны ничек күзаллауларын ачыклау өчен сораулар бирә. | А4 форматлы ак кәгазь бите, карандашлар, акбурлар, Ә. Мә-җитовның «Апрель» һәм И. Остроуховның «Иртә яз» картиналарының иллюстрацияләре. |
| **90. Кисеп ябыштыру: «Лаләлар».** | • Ике төстәге кәгазь алып, бер төсне икенчесе өстенә куеп, чәчәкләр кисәргә өйрәтү.<br>• Симметрияле кисү алымнарын (турыпочмаклы кәгазь битен урталай бөкләп, битне бөкләү сызыгы буенча тоткан килеш яртылаш кисү) ныгыту.<br>• Балаларның әйләнә-тирә дөньяны Нәфасәт и кабул итүләрен үстерү. | Якты һәм җылы яз чәчәге образы турында әңгәмә үткәреп, аның белән соклану хисләре уяту. Нәфис сүз куллану. Эш алымнарын күр-сәтү. | Ачык яшел төстәге фон, кызыл һәм кара төсләрдәге 6х4 см лы өчәр турыпочмаклык. Ачык һәм караңгы яшел төстәге 11х4 см лы ике турыпочмаклык. Сабак-лар өчен кәгазь тасма, җилем пумалалары, җилем, һәр балага салфеткалар. |
| **91. Рәсем ясау: «Әкияти гжель».** | • Балаларны рус халкының декоратив-гамәли сәнгате үрнәкләренең берсе - балчык савытларга гжель бизәге төшерү белән таныштыруны дәвам итү.<br>• Пумала белән төрле ысуллар кулланып эшләү күнекмәләрен ныгыту.<br>• Кәгазь тасмага гжель бизәге элементлары ясаганда, балаларның иҗади бизәү сәләтләрен формалаштыру. | Тәрбияченең гжель һөнәрчелеге турында сөйләве. Декоратив гамәли сәнгать предметларын һәм аерым элементлары схемаларын җентекләп карау, элементлар (чә-чәк бөресе, чәчәкләр, яфраклар) рәсемнәрен ясап күрсәтү. | А4 форматлы кәгазь битенең яртысы, акварель буяулар, төрле юанлыктагы пумала-лар, салфетка, аскуйма, су, декоратив-гамәли сәнгать предметларының һәм аерым элементлары схемасының иллюстрацияләре. |

| Апрель. 1 нче атна | | | |
|---|---|---|---|
| **92. Рәсем ясау: «Әкияти кош».** | • Гжель бизәкләренең яңа элементларын (кош һәм ат) ясау алымнары белән таныштыру.<br>• Предмет силуэтларын гжель чәчәк бәйләмнәре белән бизәү күнекмәсен ныгыту.<br>• Силуэтларны бизәүдә балаларның иҗади активлыкларын, мөстәкыйльлекләрен үстерү. | Гжель һөнәрчелеге турында әңгәмә үткәрү. Гжель бизәкләренең яңа элементларын (кош һәм ат) ясау схемаларын карау, аларны ясап күрсәтү. Гжель чәчәк бәйләмнәрен, ат яки кошларны рәсемдә кайда урнаштыруны бергәләп хәл итү. | Чәйнек, тәлинкә силуэтлары, акварель буяулар, төрле юан-лыктагы пумалалар, салфеткалар, аскуйма, су, декоратив-гамәли сәнгать предметларының һәм аерым элементларын ясау схемаларының иллюстрацияләре. |
| **93. Әвәләп ясау: «Крепость» (күмәк эш).** | • Пластилиннан ясалган кирпечләрдән корырга, крепость сурәтен төзергә өйрәтү.<br>• Үзара килешеп, күмәк эшләү күнекмәсен ныгыту.<br>• Өстәмә предметларны әвәләп ясаганда, иҗади сәләтләрне үстерү. | Тәрбиячене<br>ң крепостьның башка биналардан аермасы турында әңгәмә үткәрүе. Бергәләп иллюстрацияләр карау, кирпеч ясау ысулларын һәм крепостьны өю эзлеклелегенең (кирпечләрне нигездә бер рәткә тезеп һәм нигез өстенә стена күтәреп, стеналарда тәрәзә уемнары калдырып) бергәләп хәл итү. | Пластилин, әвәләп ясау такталары, салфеткалар, сыгылмалы таякчык. |
| **94. Рәсем ясау: «Төзелеш»** | 1• Балаларга, транспортка хас үзенчәлекләрне (төзелгән катлар саны, кран, бульдозер кебек махсус машиналар) рәсемгә төшерергә өйрәтүне дәвам итү.<br>• Алгы һәм ерак пландагы предметларны күрсәтеп, сюжет сурәтләү күнекмәсен ныгыту.<br>• Балаларны үз рәсемнәре турында сөйләүгә этәрү. | Иллюстрацияләр карау, якындагы төзелешкә экскурсия вакытында күргәннәр турында әңгәмә үткәрү. Төзелеш машиналарының өлешләре, формалары, детальләре үзенчәлекләрен табу, балалар эшчәнлегенә бәя бирү. | А4 форматлы кәгазь бите, төсле карандашлар, иллюстрацияләр, уенчык машиналар. |
| **95. Кору: «Кояшлы шәһәр архитек-торлары».** | • Балаларда архитектор профессиясе турында күзаллау уяту. Үзләре ниятләгәнчә биналар коруда күнекмә бирү.<br>• Чынбарлыкта әлегә булмаган, ләкин киләчәктә төзеләчәк йортларны күз алдына китереп эшләүгә ирешү. | Н. Носовның «Белмәмеш Кояшлы шәһәрдә» әсәренә ясалган иллюстрацияләрне бергәләп карап, игътибарны бирем эчтәлегенә юнәлтү. Әсәр эчтәлеге турында фикер | Гадәти булмаган йортлар рәсемнәре, кору материаллары җыелмасы яки «Лего». |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | • Бинаны корганда сабырлык һәм пөхтәлек тәрбияләү. | алышу, уен ситуациясе тудыру. Гадәти булмаган йортлар иллюстрацияләрен карау, биналар кору кагыйдәләрен искә төшерү: бөтен өлешләренең дә булуы, бинаның төзелеше аның нинди максатларга хезмәт итүе белән бәйле булуын төшендерү. Балалар корган биналарга бергәләшеп бәя бирү. | |
| **Апрель. 2 нче атна** | | | |
| **96. Рәсем ясау: «Барлык профессияләр мөһим».** | • Алдан уйлап куелганнарны рәсемдә җиткерә белергә, эшне эзлекле төстә алып барырга, предметларны кайда урнашуларына карап һәм зурлыклары буенча киң полосада ясарга өйрәтүне дәвам итү.<br>• Балаларның профессияләр турындагы белемнәрен ныгыту, кеше тормышында хезмәтнең әһәмиятенә төшендерү; төрле профессия вәкилләренә хөрмәт һәм уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.<br>• Балаларның, рәсемне үзләре теләгәнчә төрле детальләр белән тулыландыруларына ирешеп, алдан уйлап эшли белү сәләтләрен үстерү. | Хезмәт кораллары тутырылган «Сихри капчык» дидактик уены. С. Михалковның «А что у вас?» шигырен уку, Б. Маяковскийның «Кем быть?» шигырендәге профессияләрне искә төшерү, бу шигырьләргә ясалган иллюстрацияләрне карау, балаларның нәрсә ясарга ниятләүләре турында сөйләшеп алу, эшчәнлекләренә бәя бирү. | А4 форматлы кәгазь бите, карандашлар, иллюстрацияләр. |
| **97. Кисеп ябыштыру: «Урман агачлары».** | • Төп детальләрнең кисеп ясалган өлгеләре астына кәгазь куеп, астан яктыртып аппликацияләр ясарга өйрәтүне дәвам итү.<br>• Кәгазьдән симметрияле итеп кисеп, әзер формаларны билгеле бер тәртиптә (башта ерак пландагы, аннары урта, соңыннан алгы пландагы предметлар) ябыштыру күнекмәсен кабатлау.<br>• Балаларның туган як үсемлекләре турындагы | Нәфис сүз куллану, иллюстрацияләр карау, агачлар турында сөйләшү (охшаш һәм аермалы билгеләре), эшләп күрсәтү һәм аңлата бару, балаларның эшчәнлекләрен бәяләү, хуплау. | Төрле агач рәсемнәре, әзер үрнәкләр, каен һәм чыршы өчен әзерләмәләр (ак һәм көрән төстәге турыпочмаклыклар), җилем, пу-мала, салфетка, А4 форматлы яшькелт-зәңгәр төстәге кәгазь бите. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | белемнәрен ныгыту. | | |
| **98. Рәсем ясау: «Маскарад».** | • Балаларны хәрәкәтле һәм театральләштерелгән уеннар өчен битлекләрне мөстәкыйль әзерләргә өйрәтү.<br>• Персонажның йөз-кыяфәтен җентекләп анализлау һәм рәсемдә күрсәтә белүләрен камилләштерү.<br>• Яңа төр эшчәнлек белән таныштыру аша балаларның иҗади сәләтләрен үстерү. | Маскарад турында, битлекләрне нәрсә өчен киюләре, аларны тагын кайда кулланулары, барлык битлекләрнең дә уртак билгеләре (кеше йөзен тулысынча яки өлешчә каплыйлар, күз турысында тишемнәре була) турында әңгәмә кору. Хайван кыяфәтендәге битлекләрне бергәләп карау, төп формага детальләрне ясап бетерү, «җавап тап» формасында анализ ясау. | Үзәгендә 15 см диаметрлы түгәрәк сызылган һәм күзләр өчен тишем киселгән А4 форматлы кәгазь. ПВА лейләме белән катнаштырылган гуашь, төрле зурлыктагы пумалалар, сулы банка, пумала өчен аскуйма, сал-фетка, битлек иллюстрацияләре. |
| **Апрель. 3 нче атна** | | | |
| **99. Рәсем ясау: «Галәм».** | • Балаларны сурәтләү сәнгатенең пейзаж жанры һәм аның төрләре белән таныштыруны дәвам итү.<br>• Балаларда Галәм киңлекләре һәм күк җисемнәре турында күзаллау булдыру өчен, аларны бергәләп кәгазь битендә ясау.<br>• Безне чолгап алган дөнья киңлекләре белән кызыксыну тәрбияләү. | Галәм киңлекләре һәм күк җисемнәре, космонавт профессиясенең катлаулылыгы турында әңгәмә үткәрү, космонавт А. Леоновның «Галәм таңы» иллюстрацияләрен карау. | А4 форматлы куе зәңгәр яки кара төстәге кәгазь бите, гуашь, төрле зурлыктагы пумалалар, аскуйма, су, салфетка. |
| **100. Әвәләп ясау: «Космонавт» .** | • Балаларны ел саен билгеләп үтелә торган Космонавтика көне (12 апрель), космонавтлар хезмәте белән таныштыруны дәвам итү, әлеге профессиягә хас үзенчәлекләрне әвәләп ясаганда күрсәтә белергә өйрәтү.<br>• Космонавт һәм ракетаны ясау ысулын мөстәкыйль сайлау күнекмәсен ныгыту, | Космонавтика көне, космонавт профессиясе авырлыклары турында әңгәмә корып, А. Леонов иллюстрацияләрен («Кеше планета өстендә») карап, космонавт профессиясенә хөрмәт уяту. Космонавт скафандры өлешләрен җентекләп күзәтеп, | Пластилин, әвәләп ясау өчен такталар, салфеткалар, сыгылмалы таякчык. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | өлешләрне салмак кына ялгап, сылап һәм өслекләрен тигезләп, тиешле формага китерү.<br>• Дөньяның беренче космонавтын тәрбияләп үстергән туган илебез белән горурлык хисләре тәрбияләү. | аларның пропорциональ чагыштырмаларына игътибар итеп, балаларда әлеге форма турында күзаллау булдыру. Юнәлеш бирүче сораулар кулланып, балаларны мөстәкыйль эшләүгә этәрү. | |
| **101. Рәсем ясау: «Киләчәк машиналары».** | • Дөньяда булмаган гаҗәеп машиналар уйлап таптырып, аның төп өлешләрен (кузов, ишекләре, тәрәзәләре, тәгәрмәчләре) рәсемгә төшереп, балаларның иҗади сәләтләрен үстерү.<br>• Карандашлар белән пөхтә итеп буярга күнектерү.<br>• Үз рәсемең турында сөйләргә өйрәтү. | Гаҗәеп машиналар сурәтләнгән рәсемнәрне бергәләп карап, шөгыль темасына кызыксыну уяту, ул машиналарның төрле өлешләренең кайда урнашуларын карап өйрәнү, киләчәк машиналары турында сөйләшү, балаларның мөстәкыйль эшләү омтылышларын хуплау. | А4 форматлы кәгазь бите, төсле карандашлар, гаҗәеп машиналар ясалган рәсемнәр. |
